ҖАН ЯРАСЫ

Мәетне ярмау өчен «картлык яше»н кертмәкчеләр

> 5

ПОШИ ЭЗЕННӘН

«ВТ» хәбәрчесе кышкы урманга барып кайтты

> 15

ҖУЕЛМАСЫН ХӘТЕР

Әфганстаннан совет гаскәрләре чыгарылуга – 35 ел

> 16

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 21 (29181) | Җомга | 16 февраль | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131



tatarstan.ru

УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

«КИЛӘЧӘК УЕННАРЫ»Н КАРШЫЛАП

Яңача, заманча, моңарчы күрелмәгән тамаша. Киләсе атнада Татарстан башкаласында «Киләчәк уеннары» халыкара турниры башланачак. Димәк, бөтен дөньяның игътибары кабат Казанга юнәләчәк. Оештыручылар, виртуаль дөнья һәм чынбарлыкны берләштергән бу ярышларны игътибарсыз калдырырга ярамый, диләр. Ник дигәндә, турнир тарихта беренче булуы, тәүге тапкыр Казанда оештырылуы, яңалык булуы белән дә үзенчәлекле. «Киләчәк уеннары» – нәрсә ул? Кемнәр килер? Нәрсә күрербез? Тамашадан ни көтәргә? Кешелек тарихында тәүге мәртәбә оештырыла торган ярыш турында бар мәгълүматны тупладык.

> 6–7

Ишетми калмагыз

Быел гыйнварда республикада 144 мең 615 тонна сөт савылган. Узган елның шушы ук чорындагыга караганда 10 мең тоннага күбрәк бу. Елның беренче аенда 33 мең тонна ит җитештерелгән. Әлеге күрсәткеч узган елдагыдан 4 процентка кимрәк. Шуның 7,8 мең тоннасын – сыер, 8 меңен дуңгыз, калган 17 мең тоннасын кош ите тәшкил итә. Гыйнвар аенда җәмгысы 105,3 миллион (узган елгы күрсәткечнең 94 проценты) йомырка җитештерелгән.

Татарстан туристларның иң яраткан төбәкләре рейтингында дүртенче урынга чыккан. Сораштыруда катнашкан сәяхәтчеләрнең 28,1 проценты республикада булып киткән. Аларның әйтүенчә, кунакларны бездәге мәдәният җәлеп итә икән.
«РИА Новости» төзегән исемлектә Краснодар крае (53,5%) беренче урынга чыккан. Туристлар фикеренчә, бу төбәк Кара диңгез курортлары белән яраттыра. Икенче урында – Санкт-Петербург һәм Ленинград өлкәсе (51,7%). Төньяк башкала мәдәни ял урыннары һәм Фин култыгы белән җәлеп итә. Мәскәү һәм Мәскәү өлкәсе (42,8%) – өченче. Башкала күренекле урыннары, шулай ук музей-театрлары белән данлыклы. Сәяхәтчеләр шулай ук Мәскәү өлкәсендә шәһәр яны кунакханәләренең күп булуын билгеләп үткән.

Узган ел Татарстанда исерек хәлдә рульгә утырган 13 меңгә якын йөртүче ачыкланган. 2020 елдан сәрхуш йөртүчеләр аркасында һәлак булучылар саны кимеп, 80нән 40ка калган. Бу хакта Татарстан буенча эчке эшләр министры вазыйфаларын башкаручы Алексей Соколов Дәүләт Советында сөйләде.
Алексей Соколов әйтүенчә, 2023 елда психик, нерв авыруларыннан (спиртлы эчемлек куллануга бәйле чирләрне дә кертеп) интегүче 1502 йөртүче «права»сыннан мәхрүм ителгән. Наркотикка бәйлелеге булган 350 кешенең дә таныклыгын алу турында карар чыгарылган.

Татарстанда бик нык суытты. Гидрометеоүзәк кисәткәнчә, һава температурасы төнлә –37 градуска кадәр төшәргә мөмкин. Исегезгә төшерәбез: республика 14 февральдә Скандинавиядән үтеп кергән антициклон йогынтысында калды. 17 февральгә кадәр температура нормадан 9–14 градуска түбәнрәк булачак.
Синоптиклар мәгълүматларына караганда, шимбә – 17 февральдә, берникадәр җылытып, аз гына кар явып китәчәк. Көндез һава температурасы –10...–15, төнлә –17...–22 градус чикләрендә тирбәләчәк. Якшәмбе – 18 февральдә һава температурасы көндез –6...–11 градус тәшкил итәчәк. Кар явуы ихтимал.
Киләсе атна башында кар һәм көчле җил көтелә. Көндез –3...–8, төнлә –6...–11 градус. 20 февральдә явым-төшем туктаячак. Һава температурасы сизелерлек үзгәрмәячәк.

Районнарда ни хәлләр?

Бөгелмә

Бөгелмәдә уникенче тапкыр Татарстан мәчетләре арасында мини-футбол буенча турнир узды. Чарада Лениногорск, Баулы, Бөгелмә, Азнакай һәм Ютазы районнарыннан 9 команда катнашты. Шулай ук Болгар ислам академиясе командасы да бар иде. Турнир йомгаклары буенча, беренче урынны Бөгелмә районының «Бәдер» мәчете командасы яулады, икенче урынга Бөгелмә районы мөхтәсибәте командасы ия булды. Өченче урында – Ютазы районы мөхтәсибәте командасы. («Бугульминская газета»)

Мөслим

Район үзәгендә «Җиз кыңгырау моңнары» фестивале үтте. Фестивальгә күрше районнардан һәм шәһәрләрдән ат сөючеләр җыелды. Бәйрәм ярминкә белән башланып, җыр-биюләр, кызыклы уеннар белән үрелеп барды. Ә җигүле атлар парады бәйрәмнең төп бизәге булды. Анда барлыгы 10 чана һәм 19 ат катнашты. Былел фестивальдә «Аударыш» ярышлары да үтте. Азнакай, Тукай, Минзәлә, Лениногорск районнары, Чаллы һәм Әлмәт көрәшчеләре ат өстендә бил алышты. («Мөслим-информ»)

Түбән Кама

Бөек Ватан сугышы ветераны Зиннур Дәүләткиров бер гасырлык юбилеен билгеләп үтте. Ул 1924 елда Әгерҗе районының Барҗы авылында туган. 1942 елда – унсигез яшендә сугышка чыгып китә. Күп бәрелешләрдә катнаша һәм күрсәткән батырлыклары өчен шактый орден-медальләр белән бүләкләнә. Бүген ул карчыгы Сәлимә әби белән 2 бала, 4 онык һәм 7 оныкчыкның бәхетенә куанып яши. Зиннур Дәүләткировны олуг юбилее белән район башлыгы Рамил Муллин да тәбрикләде. «Сугыш елларында күрсәткән батырлыгыгыз өчен рәхмәт! Сез – яшь буын өчен ныклык һәм батырлык үрнәге», – диде ул. (e-nkama.ru)

Лаеш

Камалышта калган Газзә секторыннан Татарстанга кайткан Рушания Закирова һәм аның гаиләсе Усад бистәсендә яңа фатирда яши башлады. Аларга торак алу өчен акча җыю эшен «Приют человека» оешмасы җитәкчесе Азат Гайнетдинов оештырды. Бу игелекле гамәлгә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» фонды, «Ярдәм» һәм «Вера в будущее» кебек оешмалар, республикадагы мәчетләр һәм эшмәкәрләр кушылды. Закировлар гаиләсен әлеге шатлыклы вакыйга белән котларга Татарстан Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева, республика мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм башкалар килде. (Татарстан Диния нәзарәтенең матбугат хезмәте)

tatarstan.ru

ОЧРАШКАНГА КАДӘР

Татарстан Рәисе Иранда булып кайтты. Ике көнлек сәфәр барышында Рөстәм Миңнеханов Президент Ибраһим Рәиси белән очрашты, министрлар белән хезмәттәшлек турында фикер алышты, Исфахан провинциясе губернаторы белән элемтәләрне ныгыту турында сөйләште.

Сәфәрнең төп вакыйгасы Рөстәм Миңнехановның Тәһранда Иран Ислам Республикасы Президенты Ибраһим Рәиси белән очрашуы булды. Ибраһим Рәиси Иранның Россия төбәкләре, аерым алганда, Татарстан белән хезмәттәшлекне үстерүгә зур кызыксынуын билгеләп үтте. Ул «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеменең бу хезмәттәшлеккә зур өлеш кертүенә аерым игътибар итте. «Россиядәге бер төбәкнең башлыгы булудан тыш, сез Владимир Путин кушуы буенча «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркемен дә җитәкләвисез. Шул рәвешле башка илләр белән эшләгәндә Россиядәге барлык мөселманнарны тәкъдим итәсез. Без бу юнәлештә зур эшчәнлек алып барырга әзер. Үсешнең нигезе итеп икътисадта, мәгарифтә, мәдәниятта хезмәттәшлек итүне күрәбез», – диде Ибраһим Рәиси Рөстәм Миңнехановка.

Татарстан Рәисе Иран Президентына хезмәттәшлекне үстерүгә шәхси игътибар биргәне өчен рәхмәт белдерде. «Без Иранга һәрвакыт рәхәтләнеп киләбез. Берничә провинциядә булдык инде. Бу эш ярдәмендә безнең предприятиеләр элемтәләр урнаштырды. Быел март аенда Тәһранда Татарстан мәдәнияте көннәре узачак», – диде ул. Очрашу барышында автомобиль төзелеше, медицина, туризм өлкәсендәге хезмәттәшлек турында да сөйләштеләр.

Ибраһим Рәиси 2018 елда Татарстанга килүен дә искә алды. «Мин сезнең республикага кабат килергә әзер. Быел көз Казанда узачак БРИКС чараларында һичшиксез катнашырга җыенам», – диде ул.

Илнең сәнәгать, рудниклар һәм сәүдә министры Аббас Алиабәди белән очрашуда Рөстәм Миңнеханов Татарстанның Иран белән бай тарихи, икътисадый һәм мәдәни элемтәләре барлыгын, хезмәттәшлек тәҗрибәсенең зур икәнен әйтте. Татарстан йөк автомобильләре, вертолетлар һәм йөк-пассажир судннолары, нефть химиясе продукциясе һәм минераль ашламалар, нефть-газ чыгару җайланмалары һәм компрессорлар, суыткыч техникасы, азык-төлек һәм товарлар, авыл хуҗалыгы, медицина һәм фармацевтика продукциясе җибәрергә тели. Аббас Алиабәди әйтүенчә, алар Иран авиакомпанияләре Россиядә җитештергән самолетлар, шулай ук медицина вертолетлары белән кызыксына.

Иранның Тышкы эшләр министрлыгында узган очрашуда Рөстәм Миңнеханов Казанда БРИКС илләре саммиты кысасында узачак чаралар белән таныштырды. Иранның икътисад һәм финанс министры Әхсән Хандузи белән очрашуда Татарстан Рәисе министрны һәм бу илнең бизнес әһелләрен 2024 елның маенда Казанда узачак «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисадый форумында катнашырга чакырды. Иранның нефть министры урынбасары, Иран Милли нефть компаниясе башлыгы Мөхсин Хоҗастәмәхр белән очрашуда яклар «Төньяк – Көньяк» халыкара транспорт коридорын гамәлгә ашыру турында сөйләштеләр. Әлеге проект Татарстандагы логистика үзәкләренә Кама һәм Идел елгалары һәм Каспий диңгезе аша Иранга юл ачарга мөмкин.

«Исфахан – Татарстан» төбәкара эшлекле форумында ике илнең алдынгы ике төбәге үзләренең икътисадый һәм инвестиция мөмкинлекләре белән таныштырды, хезмәттәшлекне үстерү юнәлешләрен билгеләделәр. Бу хакта чарадан соң узган эшлекле очрашуда Рөстәм Миңнеханов белән Исфахан провинциясе губернаторы Реза Мортазави элемтәләрне ныгыту хакында тагын бер кат фикер алыштылар.

САН

2023 елның 9 ае нәтиҗәләре буенча Татарстан һәм Иран арасындагы товар әйләнеше 2022 ел белән чагыштырганда **1,5 тапкыр** арткан һәм **162 млн** АКШ доллары тәшкил иткән.

АВЫЛДА ЭШ КҮП

Балык Бистәсе районында узган елга нәтиҗә ясап, быелга ниятләрне барладылар. Район Советының хисап сессиясендә Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин катнашты. Парламент башлыгы былтыр капиталь ремонт уздырылган 1 нче гимназиядә укытучылар һәм укучыларның хәлен белеште.

Узган ел районда 1,5 млрд сумлык продукция төяп җибәрелгән. Бу 2022 елгы күрсәткечтән 18,7 процентка күбрәк. «Район икътисадында аграр комплекс зур өлеш кертә. 121,7 мең тонна ашлык җыелды. 16,8 мең тонна сөт, ике мең тоннадан артык ит җитештерелде. 2023 елда авыл хуҗалыгы продукциясе күләме 2,5 млрд сум тәшкил итә, акчалата керем – 2,1 млрд сум», – дип сөйләде сессиядә район башлыгы Радик Исламов.

Кече хуҗалыклар үсемлекчелек һәм терлекчелекне үстерүгә, сөт юнәлешендәге минифермалар төзүгә грантлар алган. Район икътисадында кече һәм урта бизнес өлеше 37 процентны тәшкил итә. Анда 3234 кеше эшли, бу – эшкә сәләтле халыкның 24,8 проценты, шуларның 1494е – үзмәшгульләр. 2023 елда Балык Бистәсе районы 20 федераль һәм республика программасын гамәлгә ашыруда катнашкан, нәтиҗәдә 38 объект төзелгән, капиталь ремонтланган һәм төзекләндерелгән. Проблемалар турында сөйләгәндә, район башлыгы җәйге чорда су белән тәэмин итү мәсьәләсен телгә алды.

Фәрит Мөхәммәтшин фикеренчә, районның күрсәткечләрне тагын да яхшырту мөмкинлеге бар. «Татарстан Рәисе дә, Хөкүмәт тә, Дәүләт Советы да муниципалитетларга, шул исәптән Балык Бистәсе районына да тәкъдимнәр һәм барлык игелекле эшләрне гамәлгә ашыруда зур ярдәм күрсәтә», – диде ул һәм республика һәм дәүләт программаларында күбрәк катнашырга, булган мөмкинлекләрдән файдаланырга киңәш итте. «Илдәге катлаулы икътисадый һәм сәяси вазгыятькә карамастан, республикада үсеш күзәтелә. Монда районның да өлеше бар», – диде ул.

Парламент башлыгы республика халкын үзе җитештергән продукция белән тәэмин итүгә зур өлеш кертүче авыл халкына аерым рәхмәт белдерде һәм Хөкүмәтнең киләчәктә дә авылдагы җитештерүчеләргә ярдәм итәсен әйтте. Фәрит Мөхәммәтшин фикеренчә, әлеге ярдәм чаралары аграр комплекстагы хәлне яхшыртырга сәләтле. Әйтик, узган ел районда мөгезле эре терлек, савым сыерлары саны кимегән. Хәлне кече хуҗалыкларны үстерү ярдәмендә уңай якка үзгәртеп булачак. Аның өчен исә республикада махсус программалар бар.

ҺӘР ЭШНЕҢ ДӘ ҖАЕ БАР

Төп башына утыртучылар, эшчеләрнең хезмәт хакы һәм яшерең урыннарының торышы. Татарстан Дәүләт Советында ачылган язгы сессиядә халык телендә булган мәсьәләләр күтәрелде. Утырышны парламент җитәкчесе Фәрит Мөхәммәтшин үткәрде.

tatarstan.ru

Дүрт сәгать дәвам иткән чараның көн тәртибендә утыздан артык сорау торса да, күбрәк гади кешегә кагылганнарына тукталдылар. Татарстан буенча эчке эшләр министры вазыйфаларын башкаручы Алексей Соколов әйтүенчә, республикада үтерү, урлау һәм талау очраклары кимегән. Җинаятьләрнең кайбер төрләре буенча соңгы утыз елда иң түбән күрсәткечләргә ирешкәнбез хәтта.

– Узган ел Татарстанда үтерү очраклары – 13,4, талау максатында һөҗүм итү – 14,7, талау – 19,5, урлау очраклары 13,6 процентка азрак теркәлде, – диде ул.

Былтыр хокук саклаучылар мошенниклык һәм читтән торып банк картасыннан акча урлауга бәйле иң күп эш тикшергән. Сүз уңаеннан, мондый очраклар буенча былтыр 4 миллиард 224 миллион сумлык зыян салынган. Бу мәсьәләдә үзебезнең уяулык та җитми. Күпме генә сөйләп торсалар да, “туганыгыз юл һәлакәтенә эләкте” дип алдаучылар кармагына эләгүче өлкән яшьтәгеләр кимеми. Былтыр гына да шул рәвешле 50 миллион сумлык зыян салынган.

– Мондый җинаятьләрне ачыклау күрсәткече 90 процент тәшкил итте, – диде Алексей Соколов. – Әмма тоткарланган 159 кешенең барысы да (ә аларның 144е – Татарстанда яшәүче 16–23 яшьлек кешеләр) – җинаять өчен оешкан колл-үзәк курьерлары. Алар акчаны кемнән алып кая тапшырырга кирәк булуы турындагы хәбәрләрне Украинадагы затлардан алуларын белеп эш иткән.

Бу елның гыйнварында гына Аксубай көллиятендә белем алучы дүрт студент-курьерны эләктергәннәр. Алар өч ай эчендә Зәй, Чистай, Мамадыш һәм Азнакайда яшәүче әби-бабайларның 3 миллион сум акчасын алып киткән.

Алексей Соколов мошенниклыкның яңа төре турында да кисәтте.

– Алдакчылар, кесә телефонына шалтыратып, сим-картаның гамәлдә булу вакыты тәмамлану турында хәбәр итә. «Телефон номерын саклап калырга телисезме?» – дип сорыйлар. Ул арада бу кешенең Дәүләт хезмәтләре порталындагы «шәхси кабинет»ына кереп, телефонга пароль һәм логинны алмаштыру өчен яңа код җибәрәләр. Моны аңламаган телефон хуҗасы номерны саклап калу турындагы сорауга: «Әйе», – дип җавап бирә, билгеле. Шуннан соң аңа: «Сезгә код җибәрдек, шуны әйтегез», – диләр. Нәтиҗәдә Дәүләт хезмәтләре порталы аша телефон хуҗасы исеменә зур суммада кредит рәсмиләштерәләр, – дип сөйләде ул.

Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппаратының да эше җитәрлек. «Былтыр әлеге адреска – 5800гә якын, федераль Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша – 60 меңнән артык, «Халык контроле»ннән – 104 меңнән артык мөрәҗәгать кабул иттек», – дип сөйләде утырышта Татарстанда Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Сәрия Сабурская. Хәрбиләр һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итү юнәлешендә дә шактый эш башкарганнар.

– Узган ел моңа бәйле 2818 мөрәҗәгать килде. Хәрбиләр һәм аларның гаилә әгъзаларын күбрәк түләү мәсьәләләре борчый. Шулай ук, медицина ярдәме күрсәтү, хәрбиләрне эзләү яки аларны Украина хәрбиләренә алмаштыру кебек мәсьәләләр дә мөһим, – диде вәкаләтле вәкил.

Аның сүзләренә караганда, РФ Оборона министрлыгы һәм федераль омбудсмен ярдәме белән былтыр әсирлеккә эләккән сигез якташыбызны туган якка кайтарганнар. «Быел тагын биш солдат Татарстанга кайтты», – диде ул.

Хезмәт хаклары турында да сөйләштеләр. Татарстан Дәүләт хезмәт инспекциясе җитәкчесе Рөстәм Галәвев әйтүенчә, быел 1 гыйнварга республика оешма-предприятиеләренең хезмәт хакы түләү буенча 89 миллион сумга якын бурычы бар. Әҗәтләләр исемлегендә 30лап физик һәм юридик зат исәпләнә.

– Былтыр хезмәт хакы буенча бурычка бәйле 235 миллион сумнан артык акчаны түләттердек. Алдагы ел белән чагыштырганда, бу 42 миллион сумга күбрәк, – диде Рөстәм Галәвев.

Түләнмәгән миллионнар турында ишеткәч: «Мондый оешма-предприятие директорлары үзләренә дә айлык акча язмыймы?» – дип тә сорап куйды депутатлар. Иң элек үзен кайгыртучылар да очрый икән. Акча дигәннән, күптән түгел Казанга килгән Куркынычсыз интернет лигасы башлыгы Екатерина Мизулина безнең студентларның 2 мең сум күләмендә стипендия алуына шаккатып китте. «Стипендия ник шулай аз? Яшәү минимумы да 13 мең сум бит», – дип кызыксындылар сессиядә катнашкан КФУ проректоры Дмитрий Таюрскийдан. Баксаң, стипендияне федераль үзәк билгели икән.

Дөньядагы хәлләрне күреп торабыз, депутатлар да борчыла. Утырышта халыкның яшерең урыннары турында сүз чыкты. Фәрит Мөхәммәтшин вазгыятьне артык күпертмәскә киңәш итте. «Халыкның кәефе болай да мактанырлык түгел», – диде ул. Депутатлар арасында моңа бәйле борчылу бар икән, Татарстан Министрлар Кабинеты белән берлектә эш юнәлешен билгеләргә вәгъдә иттеләр.

Дәүләт Советында бер урын да бушады. Күптән түгел Татарстан Дәүләт торак инспекциясе җитәкчесе итеп билгеләнгән Александр Тыгинның депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктаттылар. Дәүләт Советы Рәисе аңа үз урынында калып торырга да киңәш итмәкче иде, тик элеккеге депутат Фәрит Мөхәммәтшин кулыннан Рәхмәт хаты алуга юк булды. Яңа урында да эш күп.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Математика

Математика һәр очракта да дөрес түгел ул. Бер карасаң, бу гайре табигый хәл булып тоела инде, мондый нәрсәләрнең булуына ышанырлык та түгел. Математика тиклем математика да без ышанганча эшләмәсен әле. Ул да шулай хыянәт иткәч, бүтән бернәрсәгә дә ышанып булмый дигән сүз бит инде бу.

Менә шундый гади генә бер гамәл. Син миңа нәрсәдер эшлисең, мин сиңа акча түлим. Әйтик, син бик кыйммәтле эш эшлисең, миллион сумлык. Һәм мин сиңа миллион сум түлим. Аннан соң син миллион сумга миннән ниндидер бер яхшы әйбер сатып аласың. Мин сиңа ул нәрсәне бирәм һәм теге эшләп тапкан миллионыңны алып калам. Син намус белән тиреңне түгеп эшләдең һәм яхшы нәрсәгә ия булдың. Барысы да гади генә.

Монда барысы да төгәл кебек инде, бернинди дә хата юк. Ике икең дүрт шикелле. Тик шундый ук гамәлне чүт кенә бүтән өлкәгә күчерәбез икән, барысы да танымаслык булып үзгәрә. Сәламәтлек өлкәсенә, мәсәлән.

Менә син тормышыңны матурларга, барысын да җайларга тырышып, көне-төне тир түгәсең. Аңа карап кына әллә ни артып китә алмыйсың, әмма дөньяң чынлап та арулана бара. Эшлисең, акча аласың, шул акчага тормышыңны корасың. Төзисең, җайлыйсың, ризык җыясың. Барысы да яхшы. Тик бер мәлне сәламәтлегең какшый башлый. Чөнки син теге вакытта көчеңне, акылыңны гына түгел, ә сәламәтлегеңне дә түктең. Көчеңне, сәләтеңне, сәламәтлегеңне акчага әйләндердең.

Акчаң бар. Менә хәзер математика кануны буенча син шул акчага түккән көчеңне, сәләтеңне, сәламәтлегеңне кире кайтарып ала алырга тиеш бит инде. Һич югында сәламәтлегеңне. Түгелгән көчне кире кайтару мәсьәләсе хәл ителмәгән. Сарыф ителгән сәләт тә кире кайтмый бугай. Сәламәтлекне кайтарып була. Һәрхәлдә, без шулай уйлыйбыз. Менә тазалык чүт кенә ныграк какшасын да, сәламәтлек сизелерлек бетсен дә, табибка барырбыз, ул безгә өеп-төеп сәламәтлек биреп җибәрер сыман тоела. Бары тик саулыкның сизелерлек дәрәҗәдә бетүе кирәк. Аз гына кимегән өчен барып йөрисе килми. Патшалар шөгыле түгел...

Математика буенча шулай булырга тиеш бит инде. Син сәламәтлегеңне биреп, акча алдың. Хәзер акчаңны биреп, сәламәтлек алырга тиешсең. Тормышның нәкъ менә шушы төшендә математика кануны эшләми башлый. Син зур өметләр белән табибка барасың, акчаңны түлисең, ә ул... сиңа сәламәтлек биреп җибәрәсе урынга дарулар төяп җибәрә. Ә дару белән сәламәтлек – икесе ике нәрсә.

Шул математика эшләмәгән өчен, син хәзер шымытыр башына утырып каласың. Сәламәтлегең дә юк, акчаң да. Кочак-кочак дарулары гына бар. Әйтү дә кыен, ишетү дә гарьлек инде мондый нәрсәне, тик әйтми дә калып булмый. Син бөтен гомереңне буена фәкать шушы даруларны алу өчен эшләгәнсеңдер кебек булып чыга. Шуның хакына сәламәтлегеңне бетергәнсең, көчеңне түккәнсең, төннәр йокламагансың... Дарулар хакына! Адәм ыстырамы...

Бер карасаң, картайган көнеңдә күбрәк дару бирсәләр дә әйбәт инде. Бу бит инде бишмәт тутырып орден-медаль тагып, чәчәкләр күтәреп басып торган кебек. Сәламәтлегеңне күбрәк бетергәнсең икән, димәк, әйбәт эшләгәнсең. Өч таблетка тотып басып торсаң, никадәр гарьлек булырга тиеш. Бөтен гомереңне өч таблетка гына тора дигән сүз бит инде... Математика буенча шулай...

Математика дөрес эшләми бу заманда. Хәрәмләшә ул.

Әйтеп кенә бактым

Ант бирәм

Риман
ГЫЙЛЕМХАНОВ

Телевизордан бер шәхси сырхауханә турында тапшыру бара. Бактың исә, шунда эшләүче «ак халатлы дуслар», авыруларга ялган диагнозлар куеп, кыйбатлы дарулар язып, дәваланулар билгеләп, үз кесәләрен калынайтып яталар икән.

Без табибларга тулысынча ышанырга өйрәнгән, аларга үлемнән коткаручы, безгә тормыш бүләк итүче итеп карыйбыз. Аякка басу өчен, соңгы күлмәкне, гафу итегез, соңгы ыштанны салып бирергә риза. Табиблар моны белә, әлбәттә. Һәм сырхауханә эшчәнлеген тикшерү күрсәткәнчә, алар ярдәм сорап килгәннәр белән озак кына әңгәмә үткәреп, аларны үзләрендә әллә ниткән яман авырулар барлыгына ышандыралар икән. Ә диагнозлар, әйткәнемчә, дөрес куелмаган. Белә торып бит бу. Дәвалау исә һәр авыруга фәлән йөзәр мең сумга төшкән, ә файдасы булмаган.

Без ул табибларга хөкем карары чыгарырга, барлык сырхауханәләр эшчәнлеген дә бер чыбыктан сөрергә җыенмыйбыз. Бу – тиешле органнар эше. Шуны гына әйтәсе килә: табиблар –хезмәт юлын антлар эчеп башлаучы һөнәр ияләре. «Гиппократ анты» дигән сүзләрне ишетмәгән-белмәгән кеше сирәктер. Ул безнең эрага хәтле V–IV гасырларда барлыкка килгән һәм фәнни медицинага нигез салучы борынгы грек табибы Гиппократка бәйле. Аннан соң инде күпме гомер үтте. Гиппократ анты урынына бездә 1971 елда «СССР табиблары анты», ә соңрак, 1999 елда «Россия табиблары анты» керттеләр, ә антның эчтәлеге артык үзгәрмәде, авыруларны намус белән дәвалау, кеше сәламәтлегенә зыян китермәү – төп шарт. Бүген кыйблабыз 180 градуска борылды, заман «герое» – акча. Әлбәттә, хезмәт өчен түләнергә тиеш, әмма намуслы хезмәт өчен. Авырулардан нинди генә юл белән булса да акча каеру – антка хыянәт итү.

Түләүле сырхауханәләргә үземнең дә мөрәҗәгать иткәнем бар, әмма иң элек мин анда эшләүчеләр турында сорашам, ягъни досье җыям. Чөнки шикләндерә. Ә нигә әле без «шәфкатьле җан»нарга шикләнеп карарга тиеш, алар бит ант иткән! Алар безнең өчен фәрештәләр булырга тиеш, алар шуңа укыганнар, әзерләнгәннәр. Үз эшләренең чын осталары булган табиблар да бар. Бар гына түгел, күп алар, әмма, бүгенге заманда сафлары сирәгәя бармый микән, дигән уйлар да күңелне борчый. Борчымас иде, мәсәлән, интернет аша диагноз кую һәм дәвалау билгеләү очраклары турында хәбәрләр ишетелгәли. Андый белгечкә үземнең дә тап булганым бар, ярый әле бераз салкын тидереп, җиңелчә генә чирләп алган идем. Ә авыруым җитди булган булса?! Бүген мин таныш табибларга яки алар тәкъдим иткән белгечләргә генә барырга тырышам.

Башка бер җырдәрәк уй килде әле. Бу дөньяда безнең җанны дәвалаучылар, бездә күркәм зәвык тәрбияләргә алынучылар да бар бит. Мин – «эстрада йолдызлары»н күз алдында тотам. Бүген татар эстрадасы йөзен дә шактый ук дәрәҗәдә акча билгели. Акча түләсәң, телевизор экраннарыннан, сәхнәдән төшмисен, радиода да синең тавыш. Һәм тамашачы нәрсә ди инде? Күп җырлаталар икән, димәк, яхшы җырчы, җырчы шундый булырга тиештер, ди.

Бәлки, кешегә җан дәвасы бирүчеләр дә ант итәргә тиештер? Алдан әйтеп куйганымча, җүләр уй инде бу, тик җүләр уй булса да, бераз уйланып карамыйбызмы соң?

ҮЛГӘННӘР ДӘ ҖЕНЕС АЛЫШТЫРА?

Рәшит
ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

Узган гасыр башында – 1908 елда Париждагы Лоншан ипподромында гадәттән тыш хәл була. Газеталар ул көнне булган ат ярышы хакында түгел, ә зәңгәр, ак һәм көрән төстәге күлмәкләр кигән өч чибәр хатын-кыз турында язалар. Аларны күпләп халык җыелган җиргә ярымшәрә килүдә гаеплиләр. Юк, алар өчесе дә өсләренә күлмәк киеп килгәннәр килүен, әмма күлмәкләре тәнгә шулкадәр сыланып тора: аларны күргән хатыннар күзләрен читкә бора һәм тизрәк ирләрен ул тирәдән алып китәргә ашыга. Җитмәсә, күлмәкләр тезгә кадәр ерылган. Газеталар яңа моданы гариплек дип тамгалый, иләмсез дигән бәя бирә. Әмма Париж дизайнеры Маргэйн-Лакруаның эластик тукымадан махсус теккән күлмәкләрне өч модельне яллап публикага махсус күрсәтүе эзсез үтми.

Әйе, егерменче гасыр башы Франциясе дизайнерны кискен гаепли, аның исеме бүтән телгә алынмый, ләкин ул башлаган революция соңрак 1920–1930 нчы елларда Европада кайтаваз бирә: яңа буын модельерлар аның эшләнмәләрен үзләренә үрнәк итеп ала һәм җәмгыятькә кертеп җибәрә. Большевиклар диктатурасы урнаштырылгач, кием-салымдагы революцион агым безнең татарларга да үтеп керә. Бүгенге татар җәмгыяте чамадан тыш бизәнгән, картаеп баручы эстрада җырчысының бот төбенә кадәр ерылган күлмәк киеп, сәхнәдә болганып йөрүен бик табигый кабул итә. Ярымшәрәлек эстрадага гына түгел, гадәти тормышка да нык үтеп керде. Мин хәтерлим: үзе дә хатын-кыз булган мәктәп директоры хатын-кыз укытучыларга дресс-код турында гел искә төшереп торуга карамастан, бик тәрбияле һәм әхлаклы булып саналган хатын-кыз укытучылар да дәресләргә челтәр кием киеп керүне чүпкә дә санамый, изүләр шулкадәр ачык: күкрәкнең яртысын күрми калу бик тырышканда да мөмкин түгел иде. Боларны күрсә, 1908 елгы француз нәрсә дип әйтер иде? Юк, мин кием, дресс-кодлар турында сөйләшүне максат итеп куймадым. Аның хәзер дресс-коды да шәрәлекне хуплый. Башына хатын-кызның традицион кием өлеше булган яулык бәйләп йөрүчеләрне кайбер оешма җитәкчеләре эшкә алмый, алса, киемне «нормага туры китерү»не таләп итә. Хәзерге Россия элиталары бер классик рус язучысының Себер авылында чит ирнең хатын-кыз башыннан яулыгын тартып алуының нинди фаҗигагә китерүен сурәтләгән әсәр язуы турында белмиләр. Белсәләр, «норма»ның нәрсә икәнен аңларлар иде.

Автор кешеләр аңында барган әверелешнең сәбәпләре турында сөйләшергә тели. Барысы да Дарвинның «Табигый сайланыш нәтиҗәсендә төрләрнең килеп чыгуы һәм яшәү өчен көрәш барышында уңай расаларны саклау» дигән китабыннан башланган дисәм, гаҗәпләнерсез, билгеле. «Монда Дарвинның ни катнашы бар?» – диярсез. Игътибар итегез: мин сезгә беренче тапкыр китапның тулы исемен китердем, исемнең расалар турындагы өлешен безгә күрсәтмиләр. Дарвин теориясе – чынлыкта британ финанс элиталары проекты. Алар бик яхшы аңлый: кешеләрне Аллаһтан ерагайтмасаң, аларның әхлагын бозып, фикерләүдән мәхрүм итеп булмый. Ягъни кол итә алмыйсың. Дарвин теориясеннән коммунизм тәгълиматы, Ницше тәгълиматы үсеп чыга. Соңгысыннан Гитлер үз идеяләрен чиләкләп чумырып ала. Килешәсездер: кешелек җәмгыятен бик зур фаҗигаләргә этәргән идеяләр.

istockphoto.com

Томас Гексли исемле кешене «Дарвин бульдогы» дип йөртәләр. Ул – атаклы язучы Олдос Хакслиның туган бабасы. Фамилияләрдәге авазларның үзгәртелүе, бәлки, бәйләнеш артык күзгә ташланып тормасын өчендер. Гексли – үз оныгын гына түгел, дөньякүләм танылган бик күп язучыны тәрбияләгән, аларның карашларына тәэсир иткән, англосакс расаның чисталыгы өчен көрәшкән кеше. Сезнең Путин авызыннан «Англосакслар безгә каршы сугыш башлады», «Англосакслар тыныч килешүгә юл куймый» дигән сүзләрен ишеткәнегез бармы? Димәк, көрәш һаман бара. Язганың аңлашылмый дип әйтергә ашыкмагыз, фикерләп укырга тырышыгыз, чөнки бу бик мөһим, үзегезнең һәм оныкларыгызның киләчәге турында сүз бара. Сез әгәр дә Казанга барып, ай-ти паркка керсәгез яисә югары технологияләргә бәйле башка шундыйрак урыннарда йөрсәгез, алардагы китап күргәзмәләренә игътибар итегез. Аларда, һичшиксез, Олдос Хакслиның «Бу гаҗәеп дөнья» дигән китабын күрми калмассыз. Китапны бүгенге элиталар үзләренең «Библия»се урынына йөртә. Анда киләчәк җәмгыяте тасвирлана. Ул җәмгыять сыйныфларга бүленгән. Өстен сыйныф грек алфавитындагы «альфа» хәрефе белән исемләнә, иң түбән коллар сыйныфын «эпсилон» дип йөртәләр. Кешеләр ана карынында түгел, пробиркада үсеп, дөньяга килә. Аларны, яралгы хәлендә үк төрлечә тәэсир ясап, я өстен сыйныф вәкиле, я кол булырга әзерлиләр. Ул җәмгыятьтә һәркем үзен бәхетле тоя, чөнки «сом» дигән синтетик наркотик куллана. Бу «гаҗәеп дөнья»дан читтә яшәүчеләр дә бар, аларны «кыргыйлар» дип атыйлар.

Безне акрын гына шул җәмгыятькә күчәргә әзерлиләр. Моның өчен әдәбият, сәнгать чараларының барысы да кулланыла. Предиктив программалаштыру дип атала бу. Баш миләрен массакүләм контрольдә тоту һәм кирәкле юнәлешкә бору өчен әдәби әсәрләр, нәфис фильмнар, музыка файдалануны күз алдында тота. Моны психологик эшкәртүнең нечкә формасы дип атыйлар. Кешеләр гаҗәпләнә: Оруэлл китапларында язганнар ничек тормышка аша, диләр. Тормышка ашсын өчен, махсус планлаштырып иҗат ителгән китаплар алар. Биографияләренә күз ташласагыз, Хаксли белән Оруэлл арасында да зур бәйләнеш булуын күрер идегез. Кешеләрне махсус рәвештә киләчәкнең шул хуҗалар һәм коллар җәмгыятенә әзерлиләр. Бу хайван инстинктларын үстермичә һәм әхлакны юк итмичә мөмкин түгел. Һәм без күрәбез: бер телефон шалтыравы нәтиҗәсендә миллионнарынниндидер билгесез банк хисапларына күчерүче, соңгы ыштанын салып бирергә әзер торучы кешеләр тәрбияләнде инде. Эксперимент гаҗәп уңышлы бара. Кешеләр уйлау сәләтен югалтып бетереп килә. Соңгы көннәрдә генә британ парламентының Лейбористлар партиясеннән депутат Шарлотта Николс үлгән кешеләргә дә җенес алыштыру хокукы бирә торган яңа закон проекты тәкъдим итте. Берәү дә депутатны психиатрик клиникага озату турында сүз кузгалтмады. Димәк, «гаҗәеп дөнья» якында инде.

Эльвира
ВӘЛИЕВА

ЮГАЛТУ АЧЫСЫ

Ярдырырга ярамый җирләргә. Бу җөмләдә өтерне кая куярга? Гамәлдәге канун, аның артыннан табиблар да бер төрле сөйләсә, дин белгечләре үзгә фикердә. Ә өлкән яшьтәге әби-бабайлар: «Җан чыккач та тилмертәләр», – дип сыкрана. Мәетне яру мәсьәләсендә якын арада ук ачыклык кирәргә мөмкин. Россия Дәүләт Думасы депутаты Айрат Фәррахов, кешене соңгы юлга озатканда кешелеклерәк булырга кирәк, дип белдерде.

livejournal.com

Өлкән яшьтәге әби-бабайлар: «Җан чыккач та тилмертәләр», – дип сыкрана.

Закон эшлиме?

– Сүз белән әйтеп аңлата торган хәл түгел: шушы арада гына авылыбызда 98 яшен тутыручы әбинең мәетен ярдылар, – ди Буа районының Норлат авылында яшәүче Гөлчәчәк Булатова. – Әби диспансеризация үткән. Каты авырулары ачыкланмаган, кан басымы да уртача булган. Хастаханәдә ятмаган, табибларга күренмәгән, кыскасы. Шуңа күрә үлгәч, мәетне мәҗбүри ярдырганнар, диделәр. Сиксәннән узган кешеләр берниндиавыруларсыз гына яшәми, билгеле. Вакыт үткән саен машина да туза бит. Адәм баласының картлык дигән авыруы да бар. Югарыда утыручылар шул хакта бераз уйлансын иде.

Вазгыять якын арада ук үзгәрмәгәе. Бу атнада Россия Дәүләт Думасы депутаты Айрат Фәррахов үз үлеме белән вафат булган өлкән яшьтәгеләрне ярудан баш тарту хокукына бәйле тәкъдимнәрен җиткерде. Яңалык нидән гыйбарәт? Бу хакта Айрат Фәрраховның үзеннән сорадык.

– Әлеге мәсьәләне күтәрүем очраклы гына түгел. Шушы арада халык җыеннарында катнашырга туры килде. Шунда миңа берничә кеше мәетне яруга бәйле сораулар белән мөрәҗәгать итте. Мәсәлән, 90 яшьтән узган туганнарының мәетен мәҗбүри ярдырттырганнар. Халык арасында бу уңайдан борчу бар. Шуңа күрә әлеге мәсьәләгә алындым да. Тагын бер кат искәртәм: сүз криминалга, судка яки полиция вәкилләренең мәеткә бәйле сораулары булган очракларга кагылмый. Без үз үлеме белән вафат булган өлкән яшьтәгеләрне күз уңында тотабыз, – дип сөйләде Дәүләт Думасына Татарстаннан сайланган депутат «ВТ» хәбәрчесенә. – Якын кешеңне югалту – һәркем өчен зур кайгы. Тик кайбер очракларда мәетне тиешенчә соңгы юлга озату урынына, төрле документлар артыннан чабып йөрергә туры килә. Әйе, моңа бәйле федераль закон бар һәм ул яхшы эшли. Әмма аны камилләштерергә кирәк. Закон нәрсә ди? Һәркемнең мәетне ярудан баш тарту хокукы бар. Бу, шул исәптән, кешеләрнең дини карашлары буенча да эшләнә. Әмма законда баш тарту ничек башкарылырга тиеш икәне төгәл билгеләнмәгән. Васыятьнамә язып калдырырга кирәкме, әллә гади хат та җитәме, аңлашылмый. Законда «шаһитлар алдында әйтеп калдырган сүзләр» кебек юллар да бар. Төрлечә фикер йөртергә урын калганлыктан, мин мондый хокукны, бәлки, Дәүләт хезмәтләре порталында аерым хезмәт итеп булдырырга кирәктер, дигән тәкъдим җиткердем.

Айрат Фәррахов фикеренчә, үлү турында белешмә бирүче оешмаларга да вакытка бәйле чик куярга кирәк.

– Якын кешең кичтән яки төнлә үлсә, бу хакта иртән мәчеткә хәбәр итәргә кирәк. Ә син белешмә ала алмыйча аптырап йөрисең. Шуңа күрә болай да хәсрәт кергән йортта киеренкелек арта. Мондый очракларны исәпкә алып, безгә бу эш кайчан һәм күпме вакыт эчендә башкарылырга тиеш икәнен төгәл билгеләргә кирәк. Мәетне соңгы юлга озатуда кешелеклерәк булыйк. Ял көнеме ул, бәйрәмме – барысы да үз вакытында эшләнсен.

Дәүләт Думасы депутаты шуны да искәртте: аңа килеп ирешкән мөрәҗәгатьләрнең берсендә туганнары мәетне үз хисапларына ярдырырга алып барырга мәҗбүр булулары турында әйткән.

– Болай булырга тиеш түгел. Законда тәгаен язылган: мәетне ярырга алып баруны патологоанатомик тикшерүне билгеләгән оешма үзе хәл итәргә тиеш. Автомобильне дә ул бирә. Якыннарын югалтучылар үз машиналарында бара яки башка берәүне яллый икән, аларга компенсация түләнсен. Моңа бәйле тарифларны расларга кирәк, – диде Айрат Фәррахов.

Тагын бер мөһим мәсьәлә «картлык яше»нә бәйле. Бүген мәетне яруда мондый чикләү юк. «Илдә фаразланган гомер озынлыгы 72–74 яшь тәшкил итә. Аны 78 яшькә кадәр күтәрү бурычы тора. Шуңа күрә хәзерге вакытта үлемгә китергән сәбәпләрне ачыклау максатыннан, 85 яшьлек кешене ярудан артык мәгънә юк, дип саныйм. Бу мәсьәләдә яшь чиге булырга тиеш, – диде әңгәмәдәшебез. – Әйе, белгечләр белән дә киңәшергә кирәктер. Табибларның ни өчен бу адымга баруы аңлашыла. Соңыннан аларга сорау тумасын дип, кагыйдә буларак, күптән табибларга мөрәҗәгать итмәгән, медицина картасында хроник авырулары күрсәтелмәгән кешеләрне, үлгәч, диагнозларын раслату өчен, ярырга җибәрәләр. Әмма карт кешенең диагнозын раслатып тору кирәкме? Безгә һәр якны да канәгатьләндерерлек чишелеш табарга кирәк».

Айрат Фәррахов үз тәкъдимнәрен Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгына да юллаган. «Әлегә җавап көтәм», – дип кенә чикләнде ул.

«Мине ярдыртма...»

Сәламәтлек саклау министрлыгыннан алынган хаттан аңлашылганча, бүген мәетне яру мәсьәләсе 2011 елның 21 ноябрендәге «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында»гы 323 нче федераль канун нигезендә расланган. Анда медицина хезмәткәренең мәетне кайсы очракта ярырга җибәрергә тиешлеге, ә кайсы вакытта белешмәне ярмыйча гына бирә алуы да билгеләнгән. Шул ук канунның 67 нче маддәсендә дини карашларга нигезләнеп, ире яки хатынының яки якын туганының (балалары, әти-әнисе, уллыка алучылар, уллыкка алынганнар, бертуган апа-сеңел, абый-энеләре, оныклары, әби-бабайлары), алар булмаса, башка туганнары, яисә законлы вәкиленең язмача гаризасы булган очракта, яки инде мәрхүм үзе исән чакта бу хакта ихтыяр белдерсә, мәетне ярмаулары турында әйтелгән.

Фикер

Казанның «Рәхмәтулла» мәчете имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт ЯСӘВИЕВ:

– Ислам динендә адәм баласы – искиткеч зур кыйммәткә ия булган зат. Аллаһы Тәгалә Корьәндә күп урында үз бәндәсен хөрмәтләү турында әйтә. Адәм баласы – Аллаһы Тәгалә тарафыннан күп нигъмәтләр белән нигъмәтләндерелгән зат. Хайваннар кебек дүрт аякта йөрмәс, ике аякта йөрер. Бөтен хайваннар аңа хезмәт итәр. Ислам динендә хәтта адәм баласының йөзенә сугу да хәрам. Шуңа күрә динебездә бокс кебек йөзне кимсетә торган спорт төрләре тыелган. Хәдистә дә пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: «Үлгән кешенең сөяген сындыру исән кешенең сөяген сындыруга тиң», – ди. Исән кешегә хөрмәт булган кебек, динебез мәрхүм-мәрхүмәләргә дә тирән хөрмәт белән карый. Шуңа күрә динебез мәетне ярдыруга нык каршы.

Мәетне кимсетүгә юл куярга да ярамый, чөнки ул – безнең кадерле кешебез. Ул – кемнеңдер газиз әткәсе, әнкәсе, әбисе, туганы, ире, якын кешесе. Шул якын кешене күрә торып, әйдә, ярсыннар дип, кем генә үз кулы белән салкын пычак астына салырга риза булсын? Шөкер, мәетләрне ярдырмаган очраклар бар. Бу хакта ишеткәч, сөенәбез. Асыл сүзебез шул: мәрхүм кеше ул – Аллаһы Тәгаләдән әҗәл җитүгә ахирәткә күчкән, җыясы ризыгы, гомере беткән зат. Бу күзлектән караганда, ярмасалар бик хәерле. Без сирәк очракта гына яру мөмкин дип саныйбыз. Әмма бездә киресе эшләнә. Бу бик кызганыч.

«Мөселманнарның мәетне җирләүгә бәйле йола үзенчәлекләрен исәпкә алып, Сәламәтлек саклау министрлыгы медицина оешмасы җитәкчеләренә, үз вәкаләтләре кысасында, вафат булган кешенең туганнарына һәрьяклап ярдәм күрсәтү турында тәкъдимнәрен җиткерде», – диелә министрлыкның матбугат хезмәте хәбәрендә.

– Бүген авылда 90–95тән узган өлкәннәр дә бар. Алар, җаныкайларым, ФАПка кергән саен: «Мине ярдыртма, бу синнән генә тора», – дип тилмереп күзгә карап торалар, – ди Минзәлә районының Куян авылы фельдшеры Вәзирә Гыйльмуллина. – Без генә хәл итә ала торган мәсьәлә түгел шул. Өлкән яшьтәгеләр даими диспансеризация үтсә, елга ике тапкыр хастаханәдә ятып чыкса, диспансер тикшеренүе узса, ярмаска дигән тәртип бар. Тик әби-бабайларның тиктомалдан гына өйдән чыгып китәсе килми шул. Моны үзләре генә эшли ала торган кешеләр дә түгел. Яннарында кемдер булырга тиеш. Яңалык чынга ашып, өлкәннәргә файдасы тисә, бик әйбәт булыр иде.

ТҮБӘНДӘГЕ ОЧРАКЛАРДА МӘЕТНЕ ЯРУ МӘҖБҮРИ:

✓көч куллану нәтиҗәсендә үлгән дип шикләнгәндә;
✓үлемгә китергән сәбәпне, авыруның соңгы клиник диагнозын ачыклый алмаганда;
✓үлгән пациентка медицина оешмасында стационар шартларда бер тәүлектән дә кимрәк вакыт эчендә медицина ярдәме күрсәтелсә;
✓дару һәм диагностика препаратларының дозасын арттыру, йә аны күтәрә алмауга шик булганда;
✓үлем профилактика, диагностика, инструменталь анестезия, реанимация, дәвалау чаралары үткәрүгә, кан һәм (яки) аның компонентларын салу операциясе вакытына яки аннан соңгы чорга; йогышлы чирләр һәм аларга шиккә; тулысынча расланып бетмәгән яман шеш авыруына; экологик һәлакәт аркасында килеп чыккан авыруларга бәйле булса;
✓йөкле, бала тапкан хатын-кыз яки 28 көнлек бала үлсә;
✓үле бала туса;
✓суд-медицина тикшерүе таләп ителсә.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

dspkazan.com

Казанның әлеге ярышларны оештыру хокукына ия булуы турында 2022 елның 16 июнендә Санкт-Петербург халыкара икътисадый форумында игълан иттеләр. Уеннарны үткәрү хокукы өчен Россиянең тагын дүрт шәһәре – Санкт-Петербург, Мәскәү, Калуга һәм Сочи көрәшкән иде. Бәхет Казанга елмайды.

УЕННАРНЫҢ 5 ЮНӘЛЕШЕ

СПОРТ: фиджитал-футбол, фиджитал-хоккей, фиджитал-баскетбол, фиджитал-машина ярышы, фиджитал-көрәш, фиджитал-скейтбординг.

ТАКТИКА: Warface+лазертаг, CS:GO+лазертаг, Standoff+лазертаг.

СТРАТЕГИЯ: Dota2, Mobile Legends, «Мир танков».

ТИЗЛЕК: компьютер уеннарын тизлеккә уйнау.

ТЕХНОЛОГИЯЛӘР: роботлар ярышы, дроннар ярышы, спорт буенча программалаштыру.

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

«Киләчәк уеннары» – гадәти һәм цифрлы спорт ярышларын берләштергән зур чара. Берсендә беләк көче кирәк булса, икенчесендә заманча технологияләр өстенлек итә. Мисал өчен: башта спортчылар футболны компьютерда уйный, аннан сәләтләрен чын футбол кырында сыный.

Мең кат сөйләгәнче, бер кат күр

Татарстанның спорт министры Владимир Леонов, турнирга санаулы көннәр калып барганда журналистлар белән очрашкач, әнә шулай диде. «Киләчәк уеннары» хакында, чынлап та, күп һәм озак сөйләргә була. Әмма аның турында сөйләп кенә бетерә торган түгел. Чөнки бу – спортчылар өчен дә, халык өчен дә, спорт дөньясы өчен дә яңа төрле ярыш форматы. Казан аңа 450 көн әзерләнде.

Сүз уңаеннан, Россия – аны кешелек тарихында тәүге тапкыр оештыручы һәм дөньяда фиджитал-спортның Бөтенроссия федерациясен төзегән беренче ил.

Акчалата бүләк

Ярышларның гомуми приз фонды – 10 млн доллар. Әлеге акча илнең төрле компанияләрен җәлеп итү ярдәмендә җыелган (мисал өчен, СИБУР, Сбербанк).

Әлбәттә, 10 млн доллар зур сумма кебек тоела. Әмма бу акчаны спортчылар һәм ярыш юнәлешләренә бүлә башласаң, әллә ни түгел дә кебек. Министр да бу акчаның тулысынча бер кешегә яисә бер командага гына бирелмәвен кат-кат искәртте.

Билетны кайдан аласы?

Билетларны махсус сайт аша сатып алырга мөмкин. Гомумән, бөтен сату-алу эше интернет аша башкарыла. Шуңа күрә дә оештыручылар алыпсатарлардан сакланырга киңәш итә.

Билет бәясе 300 сумнан башлана. Уеннарның кайбер юнәлешләренә билетлар сатылып та беткән инде. Гомумән алганда, оештыручылар 80 мең билет сатуга куйган булган. 73 проценты инде сатылып беткән. Владимир Леонов бу җәһәттән 2013 елда узган Универсиаданы да искә төшерде.

– Ачылыш тантанасына билетларның нибары 20 проценты гына сатылган иде. Ә менә ачылыштан соң... Барысы да моның нәрсә икәнен аңлады һәм кассага йөгерде, – диде ул. – Болай булмасын өчен, билет мәсьәләсен тамашачы бүгеннән кайгыртсын иде.

Алдан ук кисәтик: чараның ачылыш һәм ябылу тантаналарына билетлар сатылмаячак.

Билетлар ике төрле булачак. Гадәти билет – ярышны трибунада утырып карау өчен. «Кунакчыллык программасы» дигәнен сатып алган очракта, билет иясе өчен парковка, ял, туклану зонасы һәм башка мөмкинлекләр ачылачак. Билгеле, соңгысының бәясе дә күпкә зуррак (3 мең сум).

БИЛЕТ САТЫП АЛУ

Ничек барасы?

«Киләчәк уеннары» ярышлары «Казан Экспо» үзәге, «Ак барс» көрәш сарае, Теннис академиясе, «Татнефть Арена», Казан циркы, «Урам» паркы, Иннополис, «Трудовые резервы», IT паркта узачак. Сүз уңаеннан, тамашачыларны 19 февральдән 3 мартка кадәр «Җиңү проспекты» метро станциясеннән «Казан Экспо»га бушлай автобус йөртәчәк. Аның кайчан китәчәген Уеннарның рәсми сайтыннан карарга мөмкин.

Моннан тыш, анда кадәр шәхси машина, 197 номерлы автобус, аэроэкспресста барып җитәргә мөмкин. Уеннарга дип алган билет белән аэроэкспресста бару шулай ук бушка булачак.

Кайдан карыйсы?

Алдарак язуыбызча, турнирның ачылыш һәм ябылу тантаналарына билет сатылмаячак. Ачылышта искиткеч тамаша вәгъдә итә оештыручылар. Аны халыкка «Беренче канал»дан күрсәтәчәкләр.

– 21 февральдә ачылыш тантанасы булачак. Ул кичке җидедә башланып, ике сәгать дәвам итәчәк. Инновацияләр бик күп булачак. Ачылыш тантанасы телевидение өчен махсуслаштырылган: кайбер нәрсәләрне бары тик телевизор караучылар гына күрә алачак. Ачылышка заманча техник мөмкинлекләрне күбрәк кертергә тырыштылар, – диде Владимир Леонов, яшерен серләрне аз гына ачып.

Ярышларны исә «Матч ТВ» каналыннан, стриминг-мәйданчыклардан (әйтик, VK, twitch) күрсәтү ниятләнә һәм, аңлашылганча, трибуналарга килеп тә карарга мөмкин булачак.

Кемнәр килә?

Владимир Леонов сүзләренчә, турнирга бик күп «йолдыз»лар киләчәк. Тулы исемлекне әйтеп тә бетермиләр хәтта. Билгеле һәм халык өчен кызыклы булырдайларына тукталыйк.

Яшьләргә (бигрәк тә үсмерләргә) блогер Влад А4, Веля, Слава Бустер, җырчы Егор Крид, футболчы Артем Дзюба, Андрей Аршавин, көрәшчеләр Ринат Фәхретдинов һәм Шарабутдин Магомедов, Рафаэль Физиев, Джонни Уокер аеруча кызык булыр төсле тоела. Кайберләре белән аерым көннәрдә махсус автограф-сессияләр дә оештырылачак.

Уеннарның символлары

«Киләчәк уеннары»ның талисманы – MIRA исемле Бәхет кошы (Жар-птица). Аны Татарстан студентлары – Мария Ромашка, Алинә Хасянова һәм Дарья Сидакова уйлап тапкан.

«Киләчәк уеннары»ның трофее ике материалдан – металл һәм полимер акрилдан тора. Трофей эчендә Уеннарның биш юнәлешен чагылдырган биш пластина урын алган. Трофей эчендә ут яна, бу аны Уеннарның талисманы белән бәйләп тора. Трофейны җиңүче командаларга тапшырачаклар.

Сүз уңаеннан, Трофей ел дәвамында меңнәрләгән чакрым узып, Казан, Ульяновск, Самара, Түбән Новгород, Уфа, Оренбургта булды. Хәзер исә ул – галәмдә.

Уеннар турында фикер

Игорь СТОЛЯРОВ, «Киләчәк уеннары» проекты җитәкчесе:
– Безнең проект танылу алды һәм бу танылу арта гына бара. Безгә бу хакта сөйләү дә бик рәхәт. Без турнирны матур итеп күрсәтергә омтылдык һәм омтылабыз. Бу чара матур булсын өчен, бик күп көч түктек, матди мөмкинлекләр кулландык. Шушы уеннарның төп идеологиясе – кешенең рухи һәм физик яктан гармонияле үсеше. Без моны спорт аша һәм аны виртуаль дөнья белән кушу бәрабәренә күрсәтәбез. Фиджитал-спорт танылу алды, Россия күләмендә чемпионатлар уза, дөнья күләмендә дә узар дип өметләнәбез.

Артем ДЗЮБА, футболчы:
– Безнең илдә шундый зур турнир оештырыла. Бу, әлбәттә, горурлык хисе уята. Үз илең өчен халыкара аренада көч сынашу – бөтенләй башка хисләр инде бу. Моңын икәнен яхшы беләм. Спортчыларга шундый мөмкинлек бирелүенә сөенәм. Аларга уңышлар телим. Минем уйлавымча, компьютер уеннары кешенең үсешенә 100 процент ярдәм итә ала. Әгәр элегрәк, барысы да әле башланып кына килгәндә, моңа бик сәерсенеп карый идем, бу спорт түгел кебек тоела иде, хәзер исә моның чыннан да спорт икәнен таныргa кирәк. Аңа бик күп вакыт сарыф ителә. Мин үзем дә дусларым белән компьютер уеннары уйнарга яратам. Әмма моның белән шөгыльләнгән, бик күп күнекмәләр ясаган кешеләргә каршы уйнау мөмкин түгеллеген аңлыйм.

Егор КРИД, җырчы, Уеннарның илчесе:
– Минем тормышым киберспорт белән турыдан-туры бәйле. Төннәрен шуңа күрә йокламый идем. Бу зур чара яшьләрнең күбесенә үзләрен күрсәтергә ярдәм итәчәк. Кешеләр киберспортның күңел ачу гына түгеллеген аңлаячак. Аерым яраткан юнәлешем юк, һәрберсе үзенчәлекле. Бөтен командалар өчен дә җан атачакмын.

Илья АВЕРБУХ, фигуралы шуу буенча Олимпия чемпионы:
– Минем уйлавымча, бу – искиткеч проект, дөрес юнәлештәге хәрәкәт. Россия – һәрвакыттагыча, күп нәрсәләрдә юл ярып баручы. Барысы да югары дәрәҗәдә узачагына ышанам. Казан мондый чараларны ничек үткәрәсен белә, моны күп тапкыр дәлилләгән шәһәр дә бит ул. Катнашучыларга бераз көнләшеп тә карыйм хәтта. Мондый уеннарда катнашу – киләчәккә сикерү ул. Мин футболда көч сынашып карар идем. Виртуаль уеннарны да, кырдагысын да яратам, әмма минем уен дәрәҗәсе замана балаларыныкы кебек түгел инде. Улым да виртуаль футболны үз итә. Аның өчен дә бу Уеннар этәргеч булыр иде.

Максим ПЕСТУШКО, «Ак барс» хоккей клубы уенчысы, Уеннарның катнашучысы:
– Фиджитал формат яшьләрне сәламәт яшәү рәвешенә өндәячәк. «Киләчәк уеннары»ннан соң спортның барлык төрләренә дә игътибар артыр дип өметләнәм. Фиджитал-хоккейга килгәндә, без командага тупланугa, бозда да, компьютерда да күнегүләр ясый башладык. Исәп уртак булачак бит. Бозда да, виртуаль дөньяда да үзеңне күрсәтә белү мөһим.

Иван ЛАЗАРЕВ, «УНИКС» баскетбол клубы уенчысы, Уеннарның катнашучысы:
– Киберспорт дөньясында мин яңа кеше түгел. Узган ел фиджитал-футболны караган идем. Бик кызык, бик күңелле. «Киләчәк уеннары» – спортның без гадәтләнгән төрләре белән киберспортны берләштергән кәттә формат ул. Өметләр зурдан. Турнир мавыктыргыч булачак!

Данис ЗАРИПОВ, «Ак барс» хоккей клубының экс-капитаны, хоккейчы:
– «Киләчәк уеннары»на мөнәсәбәтем уңай. Минем өчен, әлбәттә, бу – яңа формат, спорт дөньясындагы яңа проект. Һәм бу – кызыклы проект! Биредә чынбарлыктагы мөмкинлекләрең дә сынала. Яшермим: виртуаль уеннардагы уңышларым белән әллә ни мактана алмыйм. Спортның чынбарлыктагы һәм виртуаль дөньядагы төрләрен берләштерүгә начар караштa түгелмен. Яшьләрнең күбесе андый уеннарда катнаша. Киберспортның киләчәге бар.

(Барлык мәгълүматны, чараның уздыру вакыты һәм урынын рәсми сайттан карап барырга киңәш итәбез. – **Авт.**).

22 февральдә «Татнефть Арена»да «Йолдызлар матчы» узачак. Һәм, чыннан да, командалар хоккей «йолдыз»ларыннан торачак. Бозга Данис Зарипов һәм Илья Ковальчук җитәкчелегендәге командалар чыгачак. Моннан тыш, Сергей Мозякин, Александр Семин, Евгений Артюзин, Павел Дацюк, Василий Кошечкин һәм Максим Афиногеновны күреп булачак. Алар Казан спорт мәктәпләрендә шөгыльләнүче балалар белән бергә уйнаячак.

«КИЛӘЧӘК УЕННАРЫ» – САННАРДА

21 февраль – **3** март көннәре

2 меңнән артык катнашучы

Приз фонды – **10 млн** доллар

Ярыш көннәре – **10+**

277 команда

21 дисциплина

107 ил

400 сәгать трансляция

ХАЛЫК АВАЗЫ

1 мартта сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Сәрия МИФТАХОВА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

Кайчан ачылыр?

«Халык авазы»на бер көндә бер үк эчтәлектә ике мөрәҗәгать килде.

Дәрвишләр бистәсендә яңа мунча төзегәннәр иде. Кайчан ачарлар икән? Әзер кебек тора инде ул. Нигә ачмыйлар икән? Халык сорый бит.

Исемем редакция өчен генә

Дәрвишләр бистәсендәге мунчаны моннан берничә ел элек сүткәннәр иде. Хәзер инде яңаны төзеделәр. Әмма кайчан ачылыр икән соң ул? Казанга мунчага йөрү кыйммәткә төшә. Халык азаплана. Мунча булырмы, юкмы – бик беләсебез килә. Форсаттан файдаланып, «ВТ»га рәхмәт әйтәсе килә. Газетагызны бик яратып укыйм. Бик әйбәт! Редакциядәгеләргә исәнлек телим!

«Ислам» мәчетенә йөрүче бабайлар исеменнән МӨНӘВИР абый

Казан мэриясе матбугат хезмәте:
– Казан шәһәре Совет районы администрациясе мәгълүматлары буенча, 2024 ел азагына мунча ачылырга тиеш.

Редакциядән. Казан шәһәре Думасы депутатлары белән очрашу вакытында Совет районы башлыгы Роман Фәтхетдинов та 2024 ел азагына кадәр әлеге мунчаның ачылачагын хәбәр итте. «Хәзерге вакытта эчке эшләр, проект дизайны эшләре бара. Төзү өчен җаваплы оешма үзенең вәгъдәсеннән кире кайтмый. Ел азагына мунчаны ачарга вәгъдә итәләр», – диган ул очрашуда.

Җитәкченең кадерен белегез

Быелгы буранга эчем пошты. Мондый кар-бураннарның күптән булганы юк иде бит инде. Әмма элегрәк аннан да көчлерәкләре була торган иде. Беркая чыга, йөри алмадык. Хәзер инде эш тә, колхоз да юк, халык өйдә генә. Авыл советы, инде кенә тырыша да, бөтен җирне кардан җыештырып бетерә алмый инде. Тоташ бураннар булды бит! Әмма төп юлларны чиста тоттылар.

Безнең авыл советы рәисе – Ришат Әхмәдуллович. Аның эшкә кергәненә дүртенче ел китте. Ничек булдыра ала, шулай эшли, тырыша. Барысын да тәртиптә тота. Әмма бит бу эшнең чыгымнары да зур.

Халыкны әйтәм әле. Үзара салым акчасын җыйдык, диләр дә, теләсә нәрсә сөйләп, теләсә нәрсә язып, ризасызлык белдереп тик яталар.

Бу буранлы көннәрдә Ришат дүрт көн буе трактор эзләде, ике тәүлек авыл урамнарын кардан ачтыры. Әле ярый шәхси тракторларыбыз бар, алар булышты. Аларны бит күндерергә дә кирәк.

Алай да халык бернәрсәдән канәгать түгел. Шуңа борчылам, ачуым килә. Җәйгә чыксаң, су туктауга, аптыратып бетерәләр Ришатны. Инде ул бераз эшне җайлады кебек. Барыбер ризасызлык белдереп торалар. Кешенең гайрәтен чигереп, алай сөйләшмиләр инде!

Ришат авылдан китә генә күрмәсен, дим. Аның кебек авыл советы рәисе булганы да юк әле бездә! Аңа кадәр 10 ел берәү торды. Авылга 100 метр юл салдымы икән?! Ришат килгәч кенә тәртип урнашты.

Безнең авылда үзара салым акчасын түләрлек 300 кеше бардыр. Әле алары да түлиләрме икән? Ул 300 кешенең акчасы, саный башласаң, әллә ни зур сумма түгел бит инде. Ул җыелган акчаны нәрсәгә генә тотасың?! Трактор гына да күпме тора бит!

Эчем поша инде шуңа. Ришатка бераз уңай сүз булмасмы дип, сезгә шалтыратып, аңа рәхмәт әйтәсем килә. Кызганыч, газета укымыйлар инде хәзер. Телефонга текәлгән барысы да.

Нурлат районы
Колбай-Мораса авылыннан
82 яшьлек Мөнир ФӘРДИЕВ

УКУЧЫ СҮЗЕ

«Ватаным Татарстан» газетасының һәр санынннан зур кызыксыну белән Риман Гыйлемхановның мәгънәле, хикмәтле язмаларын укып барам.

Магис ӘГЪЛЕТДИНОВ

«ЗАТЛЫ ТАМАША» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ

Айдар абый Фәйзрахмановның җырларын башка кеше җырласа, тыңлый алмыйм. Аның бәрхет тавышы, мелизматикасы аерылып тора. Уңышлар сезгә, Айдар абый!

Дания ГАЛИЕВА

«ЯШЕН СУКСЫН...» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ

Мин балачакта үзебезнең ихатада өч тапкыр күрдем шарсыман яшенне. Мин яңгыр алдыннан күрдем. Беренче тапкыр ишегалды уртасында. Шар минем алда «биеде» дә юкка чыкты. Икенче тапкыр, яңгыр алдыннан җил көчле булгач, әнкәй ишекләрне бикләп керергә кушты. Өченче тапкыр, коеп яуган яңгыр вакытында өйгә керде. Без өйдә алты кеше идек. Әнкәй, селкенмәгез дип, бармагын иреннәренә куйды. Тагын теге хәл кабатланды.

Сәйдә НӘБИУЛЛИНА

P.S. Мөрәҗәгатегезгә җавап таба алмагансыз икән, хафаланмагыз. Димәк, сорауга җавап әзерләнә. Җавап алуга, киләсе саннарда бастырып чыгарырбыз.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА
әзерләде

19 февраль | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.05 «Манзара» 16+
07.00, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00 «Кызган казан» 6+
11.00 «Выборы-2024» 12+
11.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
12.00, 22.40 «ӘЛЛӘ ЯЛГЫШ, ӘЛЛӘ ЯЗМЫШ» 16+
13.00 «Семь дней» 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
15.45 «Сөйләшергә вакыт» 16+
16.45 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Металлург» (Мг) – «Ак барс» 6+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Заман көзгесе» 6+
22.10 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
23.30 «НЕИЗВЕСТНЫЙ» 16+
00.25 «Каравай» 6+
00.50 «Җырлыйк әле!» 12+
01.45 «Таяну ноктасы» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12 +
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Онытa алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00, 00.15 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05, 03.30 «Идрис Газиев тәкъдим итә» 12+
15.25 «Ике аккош» 16+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.30 «Заман көзгесе» 6+
17.00, 19.10, 22.20, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
17.30, 00.40 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.35 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
21.55 «Кызган казан» 6+
03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ВЕЛИКАЯ. ЗОЛОТОЙ ВЕК» 12+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 «Александр Проханов. Исповедь» 18+
00.55 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «АННА МЕДИУМ» 16+
23.30 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Формула-1. Гаснут огни» 12+
06.30 «Всё о главном» 12+
07.00, 10.40, 12.55, 14.55 Новости
07.05, 21.45 Все на Матч!
09.00 I Зимние международные спортивные игры «Дети Приморья 2024»
10.45 Смешанные единоборства. UFC. Александр Волкановски против Илии Топурии 16+
11.40, 01.10 Еврофутбол. Обзор 6+
12.35 Специальный репортаж 12+
13.00 «Есть тема!»
14.25 «География спорта» 12+
15.00 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 6+
15.30 «Громко»
16.45 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Металлург» – «Ак барс»
19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Динамо» – «Салават Юлаев»
22.40 «Шелби» 16+
02.05 Дзюдо. Турнир «Большого шлема» 12+
04.00 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. «Зенит-Казань» – «Кузбасс» 6+

НТВ

04.50 «УГРО» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «СТРАХ НАД НЕВОЙ» 16+
23.15 «ВЫЖИТЬ ЛЮБОЙ ЦЕНОЙ» 16+
03.25 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.25 «Давай разведёмся!» 16+
08.25 «Тест на отцовство» 16+
10.40, 23.20 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.30 «Порча» 16+
12.55, 01.30 «Знахарка» 16+
13.30, 02.00 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.25 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «Кризисный центр» 16+
19.00 «АБРИКОСОВАЯ ГОРЕЧЬ» 16+
02.50 «6 кадров» 16+
03.05 «НЕВЕСТА» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «КОМАНДА 8» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 01.10 «ВО БОРУ БРУСНИКА» 12+
12.45, 19.55 «По горячим следам» 16+
13.25 «Освобождение» 16+
14.00, 03.30 «ОФИЦЕРЫ» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
20.10 «Ищу своих» 12+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «КОНЕЦ ИМПЕРАТОРА ТАЙГИ» 12+
02.30 «Часовые памяти» 16+
03.20 «Оружие Победы» 12+

20 февраль | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК» 16+
11.00 «Выборы-2024» 12+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ӘЛЛӘ ЯЛГЫШ, ӘЛЛӘ ЯЗМЫШ» 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего…» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.30 «Заман көзгесе» 6+
18.00 «Казаннан – Казанга» 16+
19.00, 00.40 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Соотечественники» 16+
23.00 «НЕИЗВЕСТНЫЙ» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Если хочешь быть здоровым» 16+
01.05 «Башваткыч» 12+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Онытa алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 18.20, 23.10, 04.20 «Җырлыйк әле!» 12+
09.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05 «Ком сәгате» 16+
15.25 «Ике аккош» 16+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00, 19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Халкым минем» 12+
21.25 «Ком сәгате» 16+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
03.30 «Караңгыда нурлар яктырак» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 Проект «Цивилизации» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ВЕЛИКАЯ. ЗОЛОТОЙ ВЕК» 12+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «АННА МЕДИУМ» 16+
23.30 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Магия большого спорта» 12+
06.30 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 6+
07.00, 10.00, 12.50, 15.05 Новости
07.05, 13.25, 14.25, 16.00, 18.45, 21.45, 01.00 Все на Матч!
10.05, 12.30 Специальный репортаж 12+
10.25 «География спорта» 12+
10.55, 11.50, 12.55, 13.50, 15.10 Санный спорт. Чемпионат России
11.30 «Что за спорт?» 12+
16.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Авангард» – «Автомобилист»
19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Спартак» – «Торпедо»
22.40 Футбол. Лига чемпионов. 1/8 финала
04.00 Матч! Парад 6+
04.30 Гандбол. Чемпионат России. OLIMPBET Суперлига. Женщины. ЦСКА – «Ростов-Дон» 6+

НТВ

04.50 «УГРО» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «СТРАХ НАД НЕВОЙ» 16+
23.15 «ВЫЖИТЬ ЛЮБОЙ ЦЕНОЙ» 16+
03.20 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.25 «Давай разведёмся!» 16+
08.25 «Тест на отцовство» 16+
10.40, 23.20 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.30 «Порча» 16+
12.55, 01.30 «Знахарка» 16+
13.30, 02.00 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.25 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «Кризисный центр» 16+
19.00 «ОДНА ЛЮБОВЬ НА ДВОИХ» 16+
02.50 «6 кадров» 16+
03.05 «НЕВЕСТА» 16+

ЗВЕЗДА

07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 01.20 «ВО БОРУ БРУСНИКА» 12+
12.50, 18.50 «Специальный репортаж» 16+
13.25 «Освобождение» 16+
14.00, 03.30 «ОФИЦЕРЫ» 16+
15.00 Военные новости 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Улика из прошлого» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ЛЕТЯТ ЖУРАВЛИ» 12+
02.35 «Часовые памяти» 16+

ТАШЛАМАЛАР һәм ГАРАНТИЯЛӘР HEROES.TATAR 117

- РОССИЯ ОБОРОНА МИНИСТРЛЫГЫ ХИСАБЫНА ТУПЛАНМА-ИПОТЕКА СИСТЕМАСЫ АША ТИЗ АРАДА ТОРАК САТЫП АЛУ МӨМКИНЛЕГЕ
- ХЕЗМӘТ УРЫНЫННАН ТОРАК ЯКИ ТОРАКНЫ НАЙМГА АЛЫП ТОРГАН ӨЧЕН КОМПЕНСАЦИЯ
- ХӘРБИ-МЕДИЦИНА УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ БУШЛАЙ ТИКШЕРЕНУ, ДӘВАЛАНУ һӘМ РЕАБИЛИТАЦИЯ УЗУ
- ФЕДЕРАЛЬ БЮДЖЕТ ХИСАБЫНА ГОМЕРНЕ һӘМ СӘЛАМӘТЛЕКНЕ ИМИНИЯТЛӘШТЕРУ
- 20 ЕЛ ХЕЗМӘТ ИТКӘННӘН СОҢ ТАШЛАМАЛЫ ПЕНСИЯ АЛУ ХОКУКЛАРЫ
- ХӘРБИ ХӘРӘКӘТЛӘР ВЕТЕРАНЫ СТАТУСЫ һӘМ ТИЕШЛЕ ТАШЛАМАЛАР
- КРЕДИТ һӘМ САЛЫМ КАНИКУЛЛАРЫ
- БАЛАЛАРНЫ ВУЗДА БУШЛАЙ УКЫТУ
- БАЛАЛАРГА ҖӘЙГЕ САВЫКТЫРУ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА БУШЛАЙ ЯЛ
- КОНТРАКТ БУЕНЧА ХЕЗМӘТ ИТҮЧЕ ХӘРБИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРГӘ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ СУБЪЕКТЛАРЫННАН БЕРДӘМ ӨСТӘМӘ ТҮЛӘҮЛӘР, ТАШЛАМАЛАР һӘМ ГАРАНТИЯЛӘР

БОЛГАНМАСЫН КҮҢЕЛ

Күңел болгану – барыбызга да таныш халәт. Ышерен-батырын түгел: көндәлек тормышыбызда аңа әллә ни игътибар да бирмибез. Еш кына ул, үзе барлыкка килеп, үзе бетә торган күренеш кебек кенә кабул ителә. Белгечләр исә күңел болгану җитди чир билгесе дә булырга мөмкин дип кисәтә. Аннан ничек сакланырга? Күңел болганганда хәлне ничек җиңеләйтергә?

Табиб-гастроэнтеролог Гөлчәчәк САФИНА шул сорауларыбызга ачыклык кертте.

:: Күңел ни сәбәпле болгана?

– Күңел болгану – корсак тирәсендә уңайсызлык тудырган, бик нык төкерек бүленеп чыгудан гыйбарәт булган халәт ул. Ул җитди чир барлыгы турында хәбәр бирергә дә мөмкин. Әйтик, ашказаны җәрәхәте, сидек куыгы, ашказаны асты бизе ялкынсыну кебек ашказаны эчәк-трактлы авырулары вакытында гадәттә косасы килә. Антибиотик, яман шеш авыруыннан эчә торган дарулар да еш кына күңелне болгата. Мигреньнән интеккән, баш миендә кан әйләнеше бозылган кешеләргә, йөкле хатын-кызларга таныш халәт бу. Күңел болгану гипертония, инфаркт, вируслы авырулар билгесе дә булырга мөмкин. Күп кешенең артыгын ашап ташласа да, машинада барганда да күңеле болгана. Шуңа күрә күңел болганудан котылу өчен иң элек аның ни сәбәпле пәйда булуын ачыкларга кирәк.

:: Хроник күңел болгану нидән гыйбарәт?

– Кешенең ярты ел дәвамында косасы килеп йөрсә, аны хроник күңел болгану диләр. Ул ашказаны-эчәк системасы белән баш мие эшчәнлеге арасында «элемтә» бозылу аркасында килеп чыга. Иң кызыгы: андый чакта кешене башка бернинди билгеләр дә борчымый, фәкать косасы гына килә.

:: Нинди очракта чаң сугарга кирәк?

– Кайчак күңел болганып кына калмыйча, кеше косарга, эче авыртырга, эче йомшарырга, температурасы, кан басымы күтәрелергә, баш авырту да борчырга мөмкин. Әлеге билгеләр озак вакыт дәвамында борчыса, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Бу очракта иң элек терапевтка күренеп, гастроэнтеролог, кардиолог, невролог кебек белгечләргә дә барасы булачак.

:: Ашаганнан соң күңел болганса, ни эшләргә?

– Мондый халәт еш кына ашказаны эшчәнлеге бозылганда күзәтелә. Андый чакта ашказаны тиешенчә кыскармый башлый, нәтиҗәдә ашказанындагы ризык вакытында эшкәртелми, кеше ашаганнан соң авырая, күңеле болгана башлый. Ашаганнан соң күңел болганмасын өчен дөрес тукланырга кирәк. Көне буена бер-ике тапкыр гына ашасаң яки, киресенчә, артыгын ашап ташласаң, артык майлы, калорияле яки сыйфатсыз ризык ашасаң, косасы киләчәк, билгеле.

:: Еш кына машинада барганда да күңел болгана бит әле...

ru.dreamstime.com

КҮҢЕЛ БОЛГАНУДАН КОТЫЛУ ӨЧЕН

✓Андый чакта имбир булыша. Аны чәйгә кушарга яки иртән торгач чәйнәргә мөмкин. Иң мөһиме – имбиргә аллергиягез булмасын. Әлеге ысул йөкле хатын-кызлар, хроник күңел болганудан интеккән кешеләргә аеруча файдалы.

✓Бөтнек яфрагы да косасы килүдән булыша. Моның өчен аның яфрагын чәйнәргә яки чәйгә салып эчәргә мөмкин.

✓Лимон салынган салкын су да кул астында йөрсен. Лимонның үзен генә ашасаң да, файдасы озак көттермәс. Лимонны иснәү дә күңел болганудан коткара.

✓Хуш исле эфир майлары иснәүне дә гадәткә кертегез. Шул ук бөтнек, лимон, әфлисун, лаванда майлары да файдалы. Күңел болганганда борынга берәр тамчы шундый май тамызырга кирәк.

✓Тирән итеп сулыш алу да файдалы.

– Ул вестибуляр аппарат (тәннең хәрәкәтләнүе өчен җавап бирә. – **Д.Г.**) белән күз арасындагы «бәрелеш» аркасында килеп чыга. Машинада барганда вестибуляр аппарат хәрәкәт иткәнне сизә, ә күз аны сизми. Нәтиҗәдә кешенең күңеле болгана башлый. Машинада барганда косасы килмәсен өчен юлга чыкканда җиңелчә генә ашарга, салонны җилләтеп алырга, үзең белән чиста су алырга кирәк. Суга имбир, бөтнек өстәргә дә була. Ул күңел болгануны басачак. Машинада барганда косасы килмәсен дисәң, юлда гаджетка текәлеп яки китап укып барырга да ярамый.

Тест

ОРГАНИЗМЫГЫЗГА КАЛИЙ ҖИТӘМЕ?

Моны ачыклау өчен түбәндәге гади генә сорауларга җавап бирергә кирәк. Күпчелек сорауларга «әйе» дип җавап бирсәгез, димәк, сезнең организмыгызга калий җитми дигән сүз.

1. Мускулларның хәлсезлегеннән тилмерәсезме?
2. Кан басымыгыз югарымы?
3. Эч катудан зарланганыгыз бармы?
4. Шешенүләр еш борчымыймы?
5. Сидек кудыргыч дарулар эчәсезме?
6. Исерткеч эчемлекләр кулланасызмы?
7. Спорт белән актив шөгыльләнәсезме?
8. Сез бәрәңге аз ашыйсызмы?
9. Яшелчә салатларын сирәк кулланасызмы?
10. Җиләк-җимеш, яшелчәләр аз ашыйсызмы?
11. Бәрәңге һәм яшелчәләрне әзерләгәндә озак итеп суда пешерәсезме?
12. Җиләк-җимеш, яшелчә сокларын сирәк кулланасызмы?
13. Кипкән җиләк-җимешләрне сирәк ашыйсызмы?

НӘРСӘДӘ КҮПМЕ КАЛИЙ БАР?

➤1 бәрәңгедә – 800 миллиграмм калий;
➤ярты чынаяк йөземдә – 680 миллиграмм;
➤200 грамм йогыртта – 580 миллиграмм;
➤1 стакан әфлисун согында – 500 миллиграмм;
➤1 бананда – 450 миллиграмм;
➤1 кечкенә кавында – 400 миллиграмм;
➤1 стакан сөттә – 400 миллиграмм.

*Калийның көндәлек дозасы – 2–4 грамм.

Укроп булыша

•Укроп күңел болганганда булыша.
•Шикәр чире белән авыручы кешеләргә дә бик файдалы ул. Ник дигәндә, шикәр чире үзәк нерв системасын, йөрәк, бөер, бавыр, күз, аякны зарарлый.
•Күз авыртканда, салфетканы укроп төнәтмәсендә чылатып, шуның белән 20 минутка күзләрегезне каплагыз. Моны 20 көн дәвамында кабатларга кирәк. Төнәтмә болай ясала: 1 аш кашыгы орлыкка 1 стакан кайнап чыккан су коеп, 30 минут төнәтеп сөзегез.
•Укроп төнәтмәсе эчү бала имезүче әниләрнең сөтен арттырырга булыша.
•Укроп ярдәмендә бәвел тотмауны да 1 атнада дәваларга була. Кичтән 1 аш кашыгы укроп орлыгына 1 стакан су кайнатып салыгыз да җылы урында (термос булса, яхшырак) төне буе төнәтегез. Иртән ач карынга эчегез.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

Укучы хаты

С витамины кайда?

Кышын күпчелек җиләк-җимешнең, бигрәк тә җәйдән бирле саклана торганнарының витаминнары калмый диярлек. Ә менә цитрус җимешләре, көз ахыры – кыш башында гына өлгергәнлектән, С витаминын кыш ахырына кадәр саклый. Татлы борыч, тозлы кәбестә, гөлҗимеш, миләш, яшел тәмләткечләр дә әлеге витаминга бай. Шуңа күрә кышын алардан өзелмәскә тырышам.

Кәбестәне үзем тозлыйм. Яшел суганны тәрәзә төбендә үстерәм. Гөлҗимеш белән миләшне суга салып кайнатып чыгарам да төнгә термоска тутырып калдырам. Икенче көнне көне буе эчәм. Тәмле дә, файдалы да!

Гөлфия НИЗАМОВА. Казан

Исеңдә тот!

Силикон тышлыкны чистарту

Телефонның үтә күренмәле силикон тышлыгы, бигрәк тә кояш күзендә озак торган очракта, тиз саргая, ямьсезләнә. Аны өй шартларында җиңел генә элеккеге хәленә кире кайтарырга мөмкин.

Моның өчен кер порошогы, су, аш серкәсе һәм буяу эреткеч (растворитель) кирәк. Савыт төбенә бер кат чүпрәк җәябез. Бер-ике кашык кер порошогы, берәр чынаяк җылы су салабыз. Суда чиста салфетканы чылатып алабыз. Шуннан савытка 1 аш кашыгы теләсә нинди аш серкәсе өстибез. Болгатабыз. Телефон тышлыгын алдан чылатып куелган салфеткага төреп, суга салабыз. 5 минут чамасы узгач, суга 1 чәй кашыгы буяу эреткеч өстибез. Тагын барысын бергә болгатып (болгатканда, ныграк саргайган өлешләрен чүпрәк белән ышкыйбыз), тышлыкны 30 минут тотабыз. Серкәле-порошоклы судан алгач, чиста суда чайкыйбыз. Болай эшләгәндә, тышлык, элеккеге кебек үк, үтә күренмәлегә әйләнеп калачак.

БАКЧАЧЫНЫ НИ БОРЧЫЙ?

Дөнья әле ап-ак карга күмелеп утыруга карамастан, уңган хуҗабикәләрнең уй-фикерләре инде күптән бакча, орлыклар тирәсендә бөтерелә. Һәвәскәр бакчачы Әлфинур НӘҖМЕТДИНОВА аларны борчыган кайбер сорауларга җавап бирде.

Базиликнең бар җае

? Базиликны бик яратам, ләкин аны рәтле-башлы үстерә белмим. Май ахыры – июнь башында үсентеләрен ачык туфрактагы помидорлар янына утыртып куям. Әмма ул бик начар үсә, кайберләре корый. Нилектән шулай икәнен һич аңламыйм.

Римма ЯРУЛЛИНА.
Мамадыш районы

– Яктылык һәм җылы җитми, димәк. Помидор үсентесе, ботаклар чыгарып, бик тиз үсеп китә. Ә базилик үсентесе (аны кәлшәдән үстерү әйбәт), акрын үсүе сәбәпле, күләгәдә утырып кала. Шуңа күрә үсентеләрне кояшлы, җил тими торганрак урынга утыртырга кирәк. Ә май аенда һич югы 2–3 атнага теплицага утырту әйбәт. Мондый мөмкинлек булмаса, төнгә өстен каплап куярга кирәк.

Суз уңаеннан, базилик ботактан әйбәт үрчи. Теплицага берничә үсенте утыртып, ботаклангач, аларны кисеп, суда тотарга да, тамыр җибәрә башлагач, июнь урталарында ачык туфракка утыртып куярга мөмкин.

Орлык күләме

? Кибеттән орлык ала башласам, күпме кирәк булыр икән, дип аптырыйм. Әз алсаң – җитмәс, күп алсаң, саклау вакыты чыгып әрәм булыр кебек...

Сәвия ГАЛИУЛЛИНА.
Балык Бистәсе

– Иң элек шуны белеп тору зыян итмәс: 1 кв. м мәйдандагы уңдырышлы туфрактан 2,6–3 кг томат, баклажан, татлы борыч уңышы җыеп алырга мөмкин. Кыярдан – 2–3 кг, кабак, ташкабактан – 2,5–3 кг. Кишер, чөгендер, петрушкадан – 3–4 кг. Яфраклы салат, шпинат, укроптан – 1,5–2 кг. Иртә өлгерешле кәбестәдән – 2,5–3 кг, соң өлгерешле кәбестәдән – 4,5–5 кг.

Шуннан чыгып, үзебезгә күпме орлык кирәк буласын исәпләп чыгарырга мөмкин. Уртача саннардан файдаланабыз. 10 кв. м мәйданга помидор, кәбестә утырту өчен (кәлшәдән) – 0,3–0,5 г; кыяр, кабак, ташкабак өчен 4–6 г орлык кирәк. Кишер, петрушка, базилик, яфраклы салат – 5–6 г; укроп, редис, чөгендер өчен 15–18 г орлык кирәк булачак.

Карбыз тишелми

? Карбыз орлыгы начар тишелә. Үзем әзерләгәнe дә, кибеттән сатып алганы да. Аны чәчүнең берәр серен әйтмәссезме?

Татьяна АНИСИМОВА. Казан

– Тизрәк тишелсен өчен орлыкның очын (үсенте чыгара торган өлешен) тырнак игәве белән игәүләргә яки кечкенә кайчы белән кисеп алырга кирәк. Шуннан соң орлыкларны авызы пешермичә генә эчеп була торган җылы суга салып, төнгә калдырырга. Орлыклар суда тулысынча күмелергә тиеш. Шуннан соң гына туфракка утыртырга.

Икенче төрле ысулы да бар. Карбыз орлыкларын ярты сәгатькә 50 градуслы кайнар суга салып торабыз. Шуннан соң берәр савытка дымлы пычкы чүбе эченә, мамык дисклары яки кәгазь сөлге арасына үрдерергә куябыз. Дымлы торсын өчен савыт өстен пленка белән ябабыз да җылы урынга куябыз. Җылылык 25 градус чамасы булсын, җылылык батареясына да куеп торырга мөмкин. Үргәч, иң көчлеләрен аерым савытка туфракка утыртабыз.

Тәмле булсын!

ЙӨЗЕМ БЕЛӘН ЭРЕМЧЕК ЗАПЕКАНКАСЫ

Мәдинә СӘЛИМОВА рецепты

Кирәк булачак: 500 г эремчек, 4 аш кашыгы манный ярмасы, 2 йомырка, 70 г йөзем, 3әр аш кашыгы шикәр комы һәм каймак, 20 г атланмай, ярты чәй кашыгы ваниль.

Йөземне юабыз һәм, өстенә кайнап торган су агызып, 15 минут тотабыз. Эремчекне иләк аша изәбез. Шуңа 3 аш кашыгы манный ярмасы, шикәр комы, каймак һәм ваниль өстибез. Барысын бергә болгатып, бүлмә температурасында 25 минут тотабыз.

Йомырканы күпертәбез. Йөземне судан алып сыгабыз. Эремчек катнашмасына йомырка белән йөземне салып болгатабыз.

Табаны атланмай белән майлыйбыз да төбенә калган манный ярмасын тигезләп сибәбез. Эремчек катнашмасын табага салып, 200 градуска кадәр җылытылган газ мичендә 40–45 минутка куябыз.

Белеп тор!

Аш серкәсе коткара

✓Өйгә начар ис чыкса, һәр бүлмәгә аш серкәсе салынган тәлинкә куеп чыгарга мөмкин. Ис бик тиз бетәчәк.

✓Кышын аяк киемен аш серкәсендә чылатылган чүпрәк белән сөртүдән дә яхшысы юк. Чистару гына түгел, кибеттән яңа гына алып кайткандай ялтырап калачак.

✓Линолеум, плитка яки паркет җәелгән идәнне серкәле су (бер чиләк суга ярты стакан аш серкәсе) белән юган очракта, идән яңарып, төсе җетеләнеп китәчәк.

КОТЫЛГЫСЫЗ КӨН

Кыямәт көнен башкача «хисап көне», «хөкем көне», «карар көне», «туплану көне» дип атыйлар. Коръәндә бу көндә булачы вакыйгалар гаять куркыныч итеп сурәтләнә. Кыямәт көне кайчан булыр? Бу көннән кем дә булса котыла аламы?

islam.ru

Кызыксындырган сорауларга «Әл-Мәрҗани» мәчетенең икенче имамы Аймәрат хәзрәт ХАҖИЕВ җавап бирде.

:: Ил-көндәге хәлләргә карап, җәмгыятьнең үзгәрүен күзәтеп, ахырзаман якыная, дип әйтә алабызмы инде, хәзрәт?

– Кыямәт көне мәсьәләсе бик киң һәм зур ул. Аның нечкәлекләре күп. Иң элек шуны әйтик: Кыямәт көненең кайчан киләсен без белмибез. Бу бары тик Аллаһы Тәгаләгә генә билгеле. Кайбер риваятьләрдә ул җомга көнне булыр дип әйтелә. Ахырзаман ук булмаса да, аны якынайта торган галәмәтләр инде күренә башлады.

:: Кыямәт мәхшәрләреннән кем дә булса котыла алырмы?

– Пәйгамбәребез (с.г.в.) үз хәдисләрендә адәм баласына Аллаһы Тәгаләдән, Кыямәт көне фетнәләреннән сакласаң иде, дип сорарга куша. Кыямәт көне – адәм баласы өчен авыр көн. Риваятьләрдә әйтелгәнчә, Кыямәт көне мәхшәрен Раббысына ышанып, Аллаһы Тәгаләгә якын булган кешеләр күрмәс.

Хәдисләрдә духан төтене турында сүз бар. Күңелендә иман булган кешеләрнең җанын шул төтен алыр һәм Аллаһы Тәгалә мәхшәрдә аларны шулай коткарыр диелә.

> **КЫЯМӘТ КӨНЕ ЯКЫНЛАШУНЫҢ ГАЛӘМӘТЛӘРЕ**
>
> **Уртанчы галәмәтләр**
> - вакытның тиз үтүе
> - балаларның ата-аналарына итагать итмәүләре
> - мөселманнар арасында булган низаглар
> - зина, әчкечелек арту
> - сугышлар арту
> - кешенең оятлы, гыйлеме бетү
> - хатын-кызлар саны арту.
>
> **Олы галәмәтләр**
>
> Гайсә галәйһи вә сәлләмнең, Дәҗҗалның, кеше башлы хайван Дәббәнең, Йәэҗүҗ вә Мәэҗүҗнең җир өстенә килүе, кояшның мәгърибтән чыгуы.
>
> Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Бу галәмәтләр муеннан өзелеп төшкән мәрҗән бөртекләре кебек берсе артыннан берсе тиз килер», – ди. Хәтта кулына ризык тоткан кеше аны кабарга да өлгермәс, диелә.

:: Кыямәт җиткәч, һәр кешегә биш төрле сорау бирәчәкләр, ди. Бу нинди сораулар?

– Үлгәч, Мөнкир белән Нәнкир фәрештәләр бирә торган сораулар белән бутарга кирәкми боларны. «Шул биш сорауга җавап бирмичә, Ахырзаман көнендә адәм баласының аягы урыннан кузгалмас», – диелә хәдисләрдә. Беренче сорау болайрак: «Гомереңне ничек уздың? Бу гомереңне нәрсәгә багышладың?» Ягъни, башка риваятьләрдә күренгәнчә, «Без сезгә дингә небезне, китапларны җибәрдек, сез алар белән нишләдегез?» дигән мәгънәдә. Кеше гомерен яман юлда үткәргәнме, яхшылык кылганмы – барысы да билгеле булыр.

Икенче сорау. «Яшьлегеңне ничек уздырдың?» булыр. Кайвакыт адәм балалары яшьлектә кылган гөнаһларын «яшь чак – юләр чак» дигәнгә сылтап калдыра. Бу, әлбәттә, Кыямәттә «отмазка» була алмас. Яшьлектә булган энергияне, көчне нәрсәгә юнәлдергәнбез – моңа җавап тотасы булачак.

Өченче һәм дүртенче сораулар дөньялыкта нинди юллар белән мал табуыңа, аны нәрсәгә сарыф итүгә бәйле булачак. Ягъни ул хәләл гамәлләрме, әллә инде хәрам гамәлләрме – шунысы соралачак.

Бишенче сорау. «Бу дөньяда яшәгәндә нинди гамәлләр кылдың?» дигән сорау булыр. Ягъни намаз укыдыңмы, изге эшләр эшләдеңме.

:: Кыямәт көнендә нинди күренешләр булачак? Аларны ничек тасвирлап була?

– Адәм баласы бу көнне үзенең никадәр гөнаһ һәм яхшылык эшләвен уйлап, санап уздырыр. Пәйгамбәребез, бу көнне барча кеше ялангач булыр, ди. Гайшә анабыз моны ишеткәч: «Йә, Рәсүлем! Башка ирләр миңа карар бит», – дигән. Пәйгамбәребез исә: «Ул вакытта кешенең кешедә эше булмас инде», – дип җавап кайтарган.

Коръән сүрәсендә: «Ул көндә һичкем һичкемгә ярдәм кылырга, файда итәргә тырышмас, һәркем үз хәле белән мәшгуль булып кайгыда булыр», – диелә. Әнисе, баласы янына килеп, миңа бер изгелеңне бир әле, дияр. Бала, ул минем үземә кирәк, дияр. Аннары ир хатыны янына барыр, аңардан да бер изгелеген бирүен сорар. Анысы да, үземә кирәк, дияр. Ул көндә ата үз улының гөнаһын өстенә алмас һәм киресенчә.

Соң булмасын

Гыйбрәт ал!

Адәм баласы шундый зат инде ул, белепме-белмиме, үз-үзен алдалап яшәргә ярата. «Иртәгә эшләрмен», «Икенче атнадан башлармын», «Пенсиягә чыккач йөрермен»... Бу сүзләрне кайсыбыз гына үз тормышында бер мәртәбә генә булса да әйтмәде икән? Гел шулай сәбәп табып, үз тормышыбызда игелекка урын бирүне кичектереп киләбез.

«Кайчан Коръән укырга өйрәнәсең?» – дип, кайчак берәр танышыңа сорау бирәсең. «Әле эшләрем күп, кышка керсәк, вакыт күбрәк була, шунда өйрәнермен», – дип аклана башлый бу. Намазга басарга вакыт икәнен искәртсәң дә, «Әле яшь мин, картая төшкәч тә өлгерермен», – дигән җавап ишетәсең.

«Рамазан ае җитә, быел уразага керәсеңдер бит инде», – дигән сорауга да җаваплары әзер. Янәсе, бу эше белән бер дә ураза тотарлык түгел икән, яңа эш табу белән җайларга тырышачак. Әлбәттә, берсе дә ураза тотуның, намаз укуның кирәклеген кире какмый, әмма барысының да җавап бер: «Соңрак». Әйтерсең лә, бу Җир йөзендә ничә яшькә хәтле яшәячәгебез көне-сәгате белән язылган гарантия кәгазен кулга тоттырганнар!

Ибне Гомәр разыяллаһу ганһу еш кына: «Кичкә кадәр яшәсәң, иртәнгә кадәр яшәвеңне көтмә, иртәнгә кадәр яшәсәң, кичкә кадәр яшәвеңне көтмә. Сәламәтлегеңнән авырган вакытта кирәк булачак нәрсәне ал. Яшәвеңнән үлемең өчен кирәкле нәрсәне ал», – дип әйтә торган булган.

Чынлап та шулай бит. Кеше күтәренке кәефтә, зур планнар белән йокларга ята, әмма иртән уянмый. Үземнең дә бер танышымның үндүрт яшьлек улы йоклаган җиреннән уянмады. Университетта бергә укыган дус егетнең йоклаганда йөрәге туктаган. Ул да утыз ике яшендә генә иде. «Иртәгә өйләнеп кайтам», – дип, өйдәгеләре белән кыска вакытка гына саубуллашып юлга чыгып киткән кеше өчен дә ул сәфәре соңгысы булырга – юл фаҗигасенә юлыгып, гомере өзелергә мөмкин.

Бу дөньядан китү артык зур куркыныч түгел, чөнки кайчан да булса барыбер моннан китәсе, беребез дә монда каласы түгел. Иң мөһиме – нинди халәттә китүебез. Иманлы килеш китәбезме? Игелекле гамәлләрнең дә иң өстене булган намаз укылдымы? Туганнарың белән араң нык булдымы? Әти-әниеңә яхшылык кылдыңмы? «Юк шул, булмады, өлгермәдем», – дип җавап бирергә туры килсә, бик аяныч…

Шуңа да һәр көннең кадерен белергә һәм һәр көнебездә изге гамәлләргә дә урын табарга кирәк. Раббыбыз каршысына баргач, беркем дә: «Их, ремонтны ясап бетермәдем, Төркиягә дә ял итәргә барып кайта алмадым, яңа машинада да йөри алмадым», – дип үкенмәс. Ә нәрсә өчен үкенәчәкбез соң? Бу хакта Раббыбыз Үз китабында хәбәр бирде: «Алар газапның катылыгыннан кычкырышырлар, и, Раббыбыз, безне җәһәннәмнән чыгар, элек кылган явыз

pinterest.com

эшләребездән башка изге гамәлләр кылыр идек, диярләр. Аллаһ әйтер: «Әгәр вәгазьләнә торган булсагыз, Безсезгә вәгазьләнерлек озын гомер бирмәдекме? Вә сезне вәгазьләүче Коръән һәм пәйгамбәр килмәдеме? Инде газапның ачысын татыгыз! Залимнәргә ахирәттә ярдәм юк».

(Балык Бистәсе районы Тәберде Чаллысы авылы мәчете мөгаллиме Раил хәзрәт Фәйзрахмановның шәхси сәхифәсеннән алынды)

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

ӘЛЕГЕ БИТТӘ КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ, ДОГАЛАР БУЛУ СӘБӘПЛЕ, КАДЕРСЕЗЛӘМӘВЕГЕЗ СОРАЛА

Лилия ГЫЙМАЗОВА

КАЙДА СИН, ГАРМУН?

Гармуннар тик ятмыймы? Кайсы авылларда нинди көйләр уйныйлар? Гармун уйнау традициясен саклаучылар – кемнәр алар? «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясе журналисты Айзилә Батырханова белән Татарстанның атказанган артисты, баянчы Наил Сәгъдиев «Уйнагыз, гармуннар!» тапшыруында әнә шул һәм башка сорауларга җавап эзли. Бүгенге сәхифәдә без алардан үзешчән гармунчыларның хәлен һәм әлеге тапшыруның идея-максатларын белештек.

Татар җаны

:: Мондый проект башлап җибәрү кем идеясе?

Айзилә БАТЫРХАНОВА:
– Мондый проект турында Наил Сәгъдиев күптән хыялланган. Бу – аның идеясе. Бездә бит профессиональ гармунчылар турында күп сөйләнә, кайсы гына телеканалны ачсаң да, аларның тормыш юлы, иҗатына багышланган тапшырулар күрсәтелә. Ә авылларда гомер кичерүче үзешчән гармунчылар турында моңарчы бер тапшыру да юк иде. 2022 елның ноябрендә ул әлеге идеясе турында миңа да сөйләде. «Син – иҗади кеше, бу эшкә алына аласың дип уйлыйм», – диде. Бу проект миңа бик ошады. Аны телләр комиссиясе рәисе Марат Готыф улы Әхмәтов та бик хуплады, һәм без аның хәер-догасы белән башлап та җибәрдек. «Уйнагыз, гармуннар!» тапшыруының беренче чыгарылышы 2023 елның июнь аенда эфирга чыкты.

Наил СӘГЪДИЕВ:
– Гармун – татарның җаны, һәр йортның бизәге ул. Гармунда уйнау традициясе – ата-бабаларыбыздан күчкән мирас. Безгә ничек тә шушы мирасны торгызырга, популярлаштырырга кирәк. Кызганыч, яшьләр моның белән бик кызыксынмый. Бу традицияне авылларда яшәүче әби-бабайлар яшәтә. Алар да күп түгел инде хәзер... Кайсы районда нинди көйләр уйныйлар? Ул әби-бабайларның кулларына гармун ничек килеп эләккән? Безнең шуны күрсәтәсебез килә.

:: Районнар, димәктән. Кайларда булырга өлгердегез инде?

Айзилә:
– Беренче тапшыруны Актаныш районында төшердек. Һәм без бу районны очраклы гына сайламадык. Анда һәр өйдә диярлек гармун тавышы яңгырый. Актаныштa хәтта «Гармунчылар паркы» һәм гармунчыларга һәйкәл дә бар. Гомумән, бу районда гармунга карата мөнәсәбәт яхшы. Сабада да булдык, анда гармунчылар династияләре күп икән. Сарман, Апас, Мөслим районнарында да булдык, менә хәзер Нурлатка юл тоттык. Чит төбәкләргә дә чыгабыз. Әйтик, Свердлау өлкәсендәге татар авылларына бардык. Анда ике елга бер «Уйнагыз, гармуннар!» фестивале уза икән. Урал якларында яшәүче татарларга гармунда уйнау сәләтләрен күрсәтеп китү өчен бик яхшы мөмкинлек ул. Без аларны да тапшыруыбызда күрсәттек. Моннан тыш, Чиләбе өлкәсендә булып кайттык.

> Гармун, чын мәгънәсендә, халыкны берләштерә. Нинди генә һөнәр ияләре булсалар да, авылларда яшәүчеләр, рәхәтләнеп, гармун суза. Безне хәтта кайбер район башлыклары да гармун тотып каршы ала. Марат Әхмәтов та: «Мине әле бер район башлыгының да гармун тотып каршы алганы юк, ә сезне каршы алалар», – ди. Димәк, без үтемле итеп күрсәтә алабыз.

:: Бик истә калган сәфәрләр бармы?

Наил:
– Барлык сәфәрләребез дә күңелдә калырлык. Кая гына барсак та, чәкчәк, гармун һәм якты йөз белән каршы алалар. Һәр төбәк, һәр авылда яшәүче гармунчы әби-бабайларның үзгә энергетикасы була. Аларның үзләренә генә хас хатирәләре, тарихы бар. Шуңа да аерып әйтү бик кыен. Әмма без шуны аңладык: халык мондый тапшыруларга сусаган. Ә ул, чын мәгънәсендә, бик халыкчан проект булып чыкты. Шуңа безне бик җылы каршы алалар, тапшыруларны да бик яратып карыйлар.

Яшәтәсе иде

:: Сезнең геройларны ниләр борчый?

Наил:
– Кемгәдер – гармун, кемгәдер – вакыт, кемгәдер кеше җитми. Гармунда уйный белүчеләр кими, ансамбльләр бетеп бара бит. Гармун алу да – проблема. Хәзер яңа гармуннар 70–80 мең сум тора. Авыллар өчен бу – шактый зур, ә кайберләре өчен бөтенләй күтәрә алмаслык бәя. Ләкин аларның иң зур борчуы ул – яшьләр. Безнең геройлар яшьләрнең гармунда уйнавын күрергә тели, бу традицияне саклаучылар юк дип борчылалар. Аларның гармунны яшәтәселәре килә!

Айзилә:
– Безнең тапшыруларны карап, яшьләр дә тартылсын иде. Яңа сезонда без гармун ясау һөнәрчелеге турында да сөйләргә телибез. Әйтик, республикада гармунны бары тик Айрат абый Харисов кына ясый. Ул – бердәнбер. Ә бит, һәр өйдә гармун булсын, дисәк, гармун ясаучылар белән эшләргә, андый кешеләр күбрәк булсын өчен тырышырга кирәк. Тапшыруларыбызда гармун ясауның нечкәлекләрен сөйлисе килә. Хәзер бит нинди генә һөнәрләр юк. Ә милли һөнәрчелек онытыла бара...

:: Гармунда уйный белүчеләрнең елдан-ел кимүен сез дә әйттегез. Шулай да, гармунда уйнау традициясен саклап кала алуыбызга өмет бармы?

Айзилә:
– Яшьләребез өлкәннәргә караганда азрак, дисәк тә, шөкер, бар әле алар. Мин тагын шуңа игътибар итәм: балалар арасында тартылу сизелә. Әле менә Мөслимдә дә күреп кайттык, анда балалар ансамбльләргә оешып уйный, чыгыш ясый. Бабаларыннан кызыгып өйрәнәләр икән.

> **Гармун безнең канда инде ул, генетик дәрәҗәдә «сеңгән». Бер генә музыка уен коралы да, гармун кебек, халкыбызның моңын бөтен нечкәлекләре белән, шулкадәрле матур итеп күрсәтә алмый.**

:: Тапшыруның яңа сезонында нинди дә булса яңалыклар, үзгәрешләр бармы?

Айзилә:
– Проектны башлап җибәргән вакытта, без геройларыбызның язмышына бик тукталмый идек. Хәзер инде тапшыруларны тулырак, баерак итеп әзерләргә, гармунчыларны шәхес буларак ачарга тырышабыз. Барган авылларыбызның тормышын, нәрсә белән яшәвенә дә игътибар юнәлтәбез. Әйткәнемчә, гармун ясау һөнәренә дә игътибарны арттырырга телибез. Шулай ук бу юнәлешкә фәнни яктан якын килү максатыннан да тапшырулар әзерлибез. Әйтик, гармунчылар кайда белем ала ала? Бу җәһәттән Казан дәүләт мәдәният институтында өч тапшыру әзерләдек. Киләчәктә чит төбәкләргә чыгуны да дәвам итәргә ниятлибез.

:: Бу проектны киләчәктә ничегрәк итеп күрәсез?

Наил:
– Без аның озын гомерле булуына ышанабыз. Шуңа һаман саен яңалыклар өстәргә тырышабыз. Әйтик, һәр тапшыруның ике-өч минут вакытын гармунда уйнау серләренә багышлыйсы килә. Бәлки, кемнәрнеңдер өендә гармун тик ятадыр яки кемнәрдер уйнарга өйрәнергә телидер. Андыйлар өчен бик файдалы булыр иде. Аннан соң, яшь һәм өлкән буын гармунчылары катнашында фикер алышулар да оештырасы килә. Ә һәр сезонны Казанда концерт белән тәмамларга хыялланабыз. Үзешчәннәрне башкалада җыеп, аларны зур сәхнәгә менгерәсе иде. Шул рәвешле, һәр сезонга үзенә күрә нәтиҗә ясалыр иде. Фикерләр күп, барын да әйтеп бетермибез.

Кыска гына белешмә

«Уйнагыз, гармуннар!» – Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе, «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясе һәм Казан дәүләт мәдәният институтының уртак проекты. Ул атна саен чәршәмбе көнне 9.35 сәгатьтә «Россия 1 – Татарстан» телеканалында күрсәтелә.

«УЙНАГЫЗ, ГАРМУННАР!» ТАПШЫРУЛАРЫ

21 февраль | Чәршәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.05 «Манзара» 16+
07.00, 18.15, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 18.45 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК 2» 16+
11.00 «Выборы-2024» 12+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ӘЛЛӘ ЯЛГЫШ, ӘЛЛӘ ЯЗМЫШ» 16+
13.00, 00.25 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Азбука долголетия» 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я» 12+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.15 «Кызган казан» 6+
17.45 «Таяну ноктасы» 16+
19.15 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Локомотив» 6+
20.00 «Вызов 112» 16+
23.00 «НЕИЗВЕСТНЫЙ» 16+
00.00 «Каравай» 6+
01.15 «Кәмит Җәвит» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Башваткыч» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 03.30 «Бәргәләнмә, күңел кошым» 16+
09.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
10.00 «Халкым минем» 12+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05 «Сөйләшергә вакыт» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
18.20, 23.10 «Кәмит Җәвит» 16+
20.00, 00.15 «Гаилә учагы» 16+
21.25 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.20 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
18.45 Игры Будущего
21.00 «Время»
22.00 «ВЕЛИКАЯ. ЗОЛОТОЙ ВЕК» 12+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «АННА МЕДИУМ» 16+
23.30 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Магия большого спорта» 12+
06.30 «География спорта» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.55, 17.35 Новости
07.05, 15.35, 18.45, 21.45, 01.00 Все на Матч!
10.05, 12.35 Специальный репортаж 12+
10.25 «Вы это видели» 12+
11.10, 15.00 «Сочи. 10 лет спустя» 12+
11.40 Футбол. Лига чемпионов. Обзор 6+
13.00 «Есть тема!»
14.25 «Вид сверху» 12+
16.30, 17.40, 04.00 «ЭРА МЕДВЕДЕЙ» 16+
19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Локомотив»
22.40 Футбол. Лига чемпионов. 1/8 финала

НТВ

04.50 «УГРО» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «СТРАХ НАД НЕВОЙ» 16+
23.15 «ВЫЖИТЬ ЛЮБОЙ ЦЕНОЙ» 16+
00.10 «Сегодня. Игры будущего-2024» 16+
00.30 «ВЫЖИТЬ ЛЮБОЙ ЦЕНОЙ» 16+
03.20 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30, 06.15 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.25 «Давай разведёмся!» 16+
08.25 «Тест на отцовство» 16+
10.40, 23.50 «Понять. Простить» 16+
11.45, 01.00 «Порча» 16+
12.55, 02.00 «Знахарка» 16+
13.30, 02.25 «Верну любимого» 16+
14.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «Кризисный центр» 16+
19.00 «СЖЕЧЬ ВСЁ И НАЧАТЬ ЗАНОВО» 16+
23.25 «Уютное утро» 16+
02.50 «НЕВЕСТА» 16+

ЗВЕЗДА

07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 00.00 «В ЗОНЕ ОСОБОГО ВНИМАНИЯ» 12+
13.25, 03.25 «ОФИЦЕРЫ. ОДНА СУДЬБА НА ДВОИХ» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Секретные материалы» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.20 «Донбасс. Признанный» 16+
01.50 «ТРОЙНАЯ ПРОВЕРКА» 12+

22 февраль | Пәнҗешәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.05 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК 2» 16+
11.00 «Выборы-2024» 12+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 23.10 «ӘЛЛӘ ЯЛГЫШ, ӘЛЛӘ ЯЗМЫШ» 16+
13.00, 04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
14.00 «Память сердца» 16+
14.15 «Азбука долголетия» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.30, 01.15 «Точка опоры» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Погружение на 100» 12+
21.10 «Наши герои» 16+
22.10 «Наша Республика – наше дело» 16+
00.00 «НЕИЗВЕСТНЫЙ» 16+
00.50 «Видеоспорт» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00, 00.15 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 04.20 «Кәмит Җәвит» 16+
09.30 «Гаилә учагы» 16+
10.00, 20.00 «Кызган казан» 6+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
18.20, 23.10 «Сөйләшергә вакыт» 16+
21.25 «Язмыш» 16+
03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
18.40 «Человек и закон» 16+
19.45 «Поле чудес» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ВЕЛИКАЯ. ЗОЛОТОЙ ВЕК» 12+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Прямой эфир» 16+
21.20 «АННА МЕДИУМ» 16+
23.30 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Магия большого спорта» 12+
06.30 «Вид сверху» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.55, 17.35 Новости
07.05, 15.35, 19.40, 01.00 Все на Матч!
10.05, 12.35 Специальный репортаж 12+
10.25 «Игры Будущего» 16+
11.10, 15.00 «Сочи. 10 лет спустя» 12+
11.40, 18.45 Футбол. Лига чемпионов. Обзор 6+
13.00 «Есть тема!»
14.25 «Большой хоккей» 12+
16.30, 17.40, 04.00 «ЭРА МЕДВЕДЕЙ» 16+
20.30 Футбол. Лига Европы. Раунд плей-офф

НТВ

04.50 «УГРО» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «Прошу, прости!» 16+
17.55 «Жди меня» 12+
20.00 «САМОГОН» 16+
00.10 «Сегодня. Игры будущего-2024» 16+
00.30 «Ядерная зима профессора Александрова» 16+
01.40 «Квартирный вопрос» 0+
02.35 «Дачный ответ» 0+
03.25 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ

07.15, 04.30 «Давай разведёмся!» 16+
08.15, 02.50 «Тест на отцовство» 16+
10.30, 23.15 «Понять. Простить» 16+
11.40, 00.30 «Порча» 16+
12.55, 01.30 «Знахарка» 16+
13.30, 02.00 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.25 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «Кризисный центр» 16+
19.00 «ВСЁ СМЕШАЛОСЬ В ДОМЕ АВДЕЕВЫХ» 16+
05.20 «По делам несовершеннолетних» 16+
06.10 «КАЖДОМУ СВОЁ» 16+

ЗВЕЗДА

07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 23.15 «ОТВЕТНЫЙ ХОД» 12+
12.50, 18.50 «Специальный репортаж» 16+
13.25, 02.35 «ОФИЦЕРЫ. ОДНА СУДЬБА НА ДВОИХ» 16+
15.00 Военные новости 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Код доступа» 12+
22.45 «Между тем» 12+
01.05 «ДЕНЬ КОМАНДИРА ДИВИЗИИ» 12+

23 февраль | Җомга

ВГТРК ТАТАРСТАН

21.15 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Манзара» 16+
08.00 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК 2» 16+
11.00 «Нәсыйхәт» 16+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00 «ОТЕЦ СОЛДАТА» 16+
14.00 «Актуальный ислам» 16+
14.15 «Наши герои» 16+
14.45, 01.25 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.30 «Кто мы татары?» 12+
18.00 «Родная земля» 12+
18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
20.00 «Защитники» 16+
21.00 «Соотечественники» 16+
22.00 «БОЕВАЯ «ЕДИНИЧКА» 12+
01.55 «Фолиант в столетнем переплете» 16+
02.05 Мирсәит Сөнгатуллинның юбилей кичәсе 16+
03.55 «Башваткыч» 12+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 18.20, 23.10, 04.20 «Ком сәгате» 16+
09.30, 16.30, 00.15 «Нәсыйхәт» 16+
10.00, 20.30, 02.00 «Заман көзгесе» 6+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00 «Татар халык җырлары» 16+
11.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05 ТВ фондыннан. Бакый Урманче 16+
15.00, 19.10, 22.15, 02.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
20.00 «Родная земля» 12+
21.25 «Кто мы татары?» 12+
21.55 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
01.05, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

07.00 «Доброе утро»
10.00, 12.00 Новости
10.15 «ОФИЦЕРЫ» 0+
12.15 «Мужская работа» 16+
13.10 «ЩИТ И МЕЧ» 16+
16.50 «ЛЁТЧИК» 16+
18.00 Вечерние новости
19.05 Концерт к 90-летию Василия Ланового в Кремле 12+
21.00 «Время»
21.35 «20/22» 16+
23.35 «ТОРПЕДОНОСЦЫ» 12+
01.25 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.40 «КАТЬКИНО ПОЛЕ» 12+
09.20 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 17.00, 20.00 Вести
11.40 «ЛИКВИДАЦИЯ» 16+
15.10, 01.35 «ИВАН ВАСИЛЬЕВИЧ МЕНЯЕТ ПРОФЕССИЮ» 6+
17.40 Концерт, посвящённый Дню защитника Отечества
21.15 Вести. Местное время
21.30 «ЗА ПАЛЫЧА!» 12+
23.15 «НЕБО» 12+
03.10 «НА ОБРЫВЕ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 «Третий тайм» 12+
06.30 «Большой хоккей» 12+
07.00, 10.00, 14.55 Новости
07.05, 15.00, 21.45, 00.30 Все на Матч!
10.05 «Небесная грация» 0+
10.25 «Игры Будущего» 16+
11.10 «Сочи. 10 лет спустя» 12+
11.40 Лыжные гонки. Гонка Легкова PARI
13.20, 01.55 Футбол. Еврокубки. Обзор 6+
14.25 «Формула-1. Гаснут огни» 12+
15.30 Смешанные единоборства. One FC
19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Динамо» (Минск) – СКА
22.25 Футбол. Чемпионат Германии
01.25 Фрирайд. Мировой тур 6+
02.55 «Вы это видели» 12+
04.00 Санный спорт. Чемпионат России 6+

НТВ

04.40 «ОТПУСК ПО РАНЕНИЮ» 16+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.20 «ОТСТАВНИК» 16+
10.30 «ОТСТАВНИК-2» 16+
12.25 «ОТСТАВНИК-3» 16+
14.20 «ОТСТАВНИК. ОДИН ЗА ВСЕХ» 16+
17.00 «ОТСТАВНИК. СПАСТИ ВРАГА» 16+
19.35 «ГЛАЗ ПУСТЫНИ» 16+
00.10 «Сегодня. Игры будущего-2024» 16+
00.30 «Квартирник НТВ у Маргулиса». Денис Майданов 16+
02.15 «ВЕТЕРАН» 16+

ДОМАШНИЙ

07.50, 04.35 «ТРИ ДНЯ НА ЛЮБОВЬ» 16+
10.00 «АНГЕЛ В СЕРДЦЕ» 16+
14.40 «ПОРОЧНАЯ СВЯЗЬ» 16+
19.00 «ЖЕНСКИЙ ЗАЩИТНИК» 16+
23.15 «ТЫ МОЙ» 16+
03.00 «КАЖДОМУ СВОЁ» 16+
06.15 «ИРОНИЯ ЛЮБВИ» 16+

ЗВЕЗДА

05.50 «ЭКИПАЖ МАШИНЫ БОЕВОЙ» 12+
07.05, 08.15 «Военная приемка» 12+
08.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
09.50 «Легенды армии» 12+
12.10 «СВО: компоненты силы» 16+
19.25 «НЕБЕСНЫЙ ТИХОХОД» 12+
21.20 «Специальный репортаж» 16+
22.00 «Здравствуйте, товарищи!» 16+
23.30 «Музыка+» 12+
01.45 «ЭСКАДРОН ГУСАР ЛЕТУЧИХ» 12+
04.30 «Хроника Победы» 16+
04.55 «Оружие Победы»

24 февраль | Шимбә

ТАТАРСТАН
08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+
07.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 16+
09.00, 03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00 «Туган авылым» 12+
11.30, 00.40 «Музыкальный майдан» 16+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
13.30 «Гаилә учагы» 16+
14.00 «Гомер тәлгәшләре» 12+
16.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
16.30 «Дуслык илендә» 12+
16.45 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Амур» 6+
19.30, 21.30 Новости в субботу 16+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «Сөйләшергә вакыт» 16+
23.00 «КЛАД» 16+
01.05 «УЕННАН УЙМАК» 16+
03.10 «Башваткыч» 12+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Оныта алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 00.45 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
07.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 16+
09.00 «Сөйләшергә вакыт» 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00, 18.15, 03.00 «Башваткыч» 12+
12.05, 19.05, 03.50 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 Эдуардо де Филиппо. «Гаугалы гаилә». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
17.15 «Казаннан – Казанга» 16+
17.45, 05.05 «Халкым минем» 12+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30 «Мин бу җирне матурларга тудым»
22.30 Т.Миңнуллин. «Йөрәк маем». Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
01.35 «Идрис Газиев тәкъдим итә» 6+
02.25 «Җиз кыңгырау моңнары» 16+
04.40 «Заман көзгесе» 6+
05.30 «Нәсыйхәт» 16+

1 КАНАЛ
07.00 «Доброе утро. Суббота»
09.00 «Умницы и умники» 12+
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00, 12.00 Новости
10.15 «Награды России» 16+
11.05 Специальный репортаж 16+
12.15 К 80-летию актёра. «Янковский» 12+
13.35 «ЩИТ И МЕЧ» 16+
16.35 «Сегодня вечером» 16+
18.00 Вечерние новости
18.35 Гала-концерт фестиваля «Своих не бросаем» 12+
21.00 «Время»
21.35 «20/22» 16+
23.35 «ПРОВЕРКА НА ДОРОГАХ» 16+
01.25 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1
06.05 «НЕ ГОВОРИТЕ МНЕ О НЁМ» 12+
08.00 Вести. Местное время
08.20 Местное время. Суббота
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Боря» 16+
11.55 «Доктор Мясников» 12+
13.00 «ЛИКВИДАЦИЯ» 16+
17.50 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «НАРИСУЙ МЕНЯ СЧАСТЛИВОЙ» 12+
00.35 «НЕСКОЛЬКО ШАГОВ ДО ЛЮБВИ» 12+
04.10 «ЧЕГО ХОТЯТ МУЖЧИНЫ?» 16+

МАТЧ ТВ
06.00 Матч! Парад. Лучшие голы 6+
06.30, 03.40 «Что за спорт?» 12+
07.00, 10.00, 12.15, 15.30, 19.30 Новости
07.05, 15.35, 19.35, 00.30 Все на Матч!
10.05 «Команда МАТЧ» 0+
10.25 «Игры Будущего» 16+
11.10 «Якушин. Первый среди первых» 12+
12.25 Наши в UFC 16+
13.55 Гандбол. Чемпионат России. OLIMPBET Суперлига. Женщины. «Ростов-Дон» – «Черноморочка»
16.30, 04.00 Лёгкая атлетика. Чемпионат России в закрытых помещениях 6+
19.00 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 6+
20.25 Футбол. Чемпионат Германии
22.30 Смешанные единоборства. Лига «Южный рубеж»
01.25 «Формула-1. Гаснут огни» 12+
01.55 Баскетбол. Фонбет Чемпионат России – Премьер-лига. Женщины. «Динамо» – «Енисей» 6+

НТВ
04.55 «ДВОЕ» 16+
02.10 «ДВОЕ» 16+
06.20 «Жди меня» 12+
07.25 «Смотр» 0+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «Поедем, поедим!» 16+
09.20 «Едим дома» 0+
10.20 «Главная дорога» 16+
11.00 «Живая еда» 12+
12.00 «Квартирный вопрос» 0+
13.00 «Основано на реальных событиях» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «Следствие вели…» 16+
17.15 «ОТСТАВНИК. ЗАЩИТА ДЕДОВА» 16+
19.00 «Центральное телевидение»
21.50 «СВИДЕТЕЛЬ» 16+
00.10 «Сегодня. Игры будущего-2024» 16+
00.30 «ПРАЗДНИК» 16+
03.35 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ
09.40 «Уютное утро» 16+
10.05 «ДРУГОЙ МУЖЧИНА» 16+
14.40 «ПРАВО НА ИЗМЕНУ» 16+
19.00 «ДОБРОТА» 16+
22.45 «АНГЕЛ В СЕРДЦЕ» 16+
02.50 «СЛАБОЕ ЗВЕНО» 16+
06.10 «ТЫ МОЙ» 16+

ЗВЕЗДА
05.10 «ОПАСНЫЕ ТРОПЫ» 12+
06.05 «САМЫЙ СИЛЬНЫЙ» 6+
08.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
08.15 «Морской бой» 6+
09.20 «АТАКА» 12+
11.10 «Мужики» 16+
11.40 «СССР. Знак качества» 12+
12.30 «Не факт!» 12+
13.15 «Легенды науки» 12+
14.00 «Главный день» 16+
14.50 «Время героев» 16+
15.10 «ОПЕРАЦИЯ «ТАЙФУН». ЗАДАНИЯ ОСОБОЙ ВАЖНОСТИ» 16+
19.25 «НОЛЬ-СЕДЬМОЙ» МЕНЯЕТ КУРС» 16+
21.20 «Галерея Звезд» 12+
22.55 «ДУЭЛЯНТ» 16+
01.15 «ПРАВО НА ВЫСТРЕЛ» 12+
02.40 «В НЕБЕ «НОЧНЫЕ ВЕДЬМЫ» 12+
04.00 «СВИНАРКА И ПАСТУХ» 12+

25 февраль | Якшәмбе

ТАТАРСТАН
08.00 Местное время. Воскресенье

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00 «Ялантауга ай кунган» 16+
08.00, 13.00 «Адымнар» 16+
08.30 Мультфильмы 6+
08.45 «Әти һәм мин» 0+
09.15 «Тамчы-шоу» 0+
09.45 «Яшьләр тукталышы» 0+
10.15 «Кызган казан» 6+
11.00 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество» 16+
13.30 «Погружение на 100» 12+
13.40 «Татар сүзе» 12+
14.00 «ҮКСЕЗЛӘР» 16+
16.00 «Ком сәгате» 16+
17.00 «Видеоспорт» 16+
17.30 «Соотечественники» 16+
18.00 «Башваткыч» 12+
19.00, 22.00 «Семь дней» 16+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30 «Профсоюз – союз сильных» 16+
20.45 «Батырлар» 6+
21.00 «Сөйләшергә вакыт» 16+
23.00 «МИСТЕР ОЛИМПИЯ» 12+
00.50 «Янам мәхәббәт ялкынында» 16+
02.00 «Манзара» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм…» 12+
05.50 Татарстан хәбәрләре 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00 «Заман көзгесе» 6+
06.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять»
07.00 «Адымнар» 16+
07.30 «Кто мы татары?» 12+
08.00 «Бахетемә юрадым» 16+
09.00, 03.40 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
10.00 «Кызган казан» 6+
10.30 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05, 00.40 «Яшьләр тукталышы» 6+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00, 04.35 «Гаилә учагы» 16+
13.30 «Ялантауга ай кунган» 16+
15.30 «ҮКСЕЗЛӘР» 16+
17.15, 21.00 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит» 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате» 16+
20.00 «Семь дней» 16+
21.50 Юлчы. «Аерылабыз, ахрысы». Әлмәт татар дәүләт драма театры спектакле 16+
01.05 «Манзара» 16+
02.45 «Шаян хәлләр» 16+
03.15 «Әдәби хәзинә» 6+
05.00 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ
06.00, 10.00, 12.00 Новости
06.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
07.40 «Часовой» 12+
08.10 «Здоровье» 16+
09.20 «Мечталлион» 12+
09.40 «Непутевые заметки» 12+
10.15 «Играем свадьбу!» 12+
11.05 «Жизнь других» 12+
12.15 «Повара на колесах» 12+
13.10 «Видели видео?» 0+
14.55 К 50-летию фильма «Семнадцать мгновений весны» 16+
17.05 «Медицинский спецназ» 16+
18.00 Вечерние новости
19.00 «Лучше всех!» 0+
21.00 «Время»
23.00 «АБРЕК» 16+
00.00 ПОСЛЕСЛОВИЕ…» 18+
01.25 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1
06.10, 01.05 «ШЁПОТ» 12+
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома»
09.25 «Утренняя почта»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 17.00 Вести
11.50 «Большие перемены»
12.50 «ЛИКВИДАЦИЯ» 16+
17.50 «Песни от всей души» 12+
20.00 Вести недели
22.00 Москва. Кремль. Путин
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+

МАТЧ ТВ
06.00 Смешанные единоборства. UFC
09.00, 10.00, 12.15, 15.40 Новости
09.05, 15.45, 19.00, 22.30, 00.45 Все на Матч!
10.05 «Команда МАТЧ» 0+
10.25 «Игры Будущего» 16+
11.10 «Игорь Численко. Удар форварда» 12+
12.25, 04.00 Лёгкая атлетика. Чемпионат России в закрытых помещениях 6+
16.55, 22.40 Футбол. Чемпионат Италии
19.30 Смешанные единоборства. АСА
01.25 «География спорта» 12+
01.55 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. «Динамо-ЛО» – «Белогорье» 6+

НТВ
04.55 «ПОСЛЕДНИЙ ГЕРОЙ» 16+
06.30 «Центральное телевидение» 16+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача» 16+
11.00 «Чудо техники» 12+
12.00 «Дачный ответ» 0+
13.00 «НашПотребНадзор» 16+
14.05 «Однажды…» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «Человек в праве» 16+
17.00 «Следствие вели…» 16+
18.00 «Новые русские сенсации» 16+
19.00 «Итоги недели»
20.20 «Маска» 12+
00.10 «Сегодня. Игры будущего-2024» 16+
00.30 «РУССКИЙ ХАРАКТЕР» 16+
02.25 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+
03.25 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ
10.00 «Пять ужинов» 16+
10.15 «СЕКРЕТЫ ЛИЗЫ» 16+
14.45 «ТАЙНЫЕ МЕЧТЫ АЛИСЫ» 16+
19.00 «ДОБРОТА» 16+
22.55 «ИРОНИЯ ЛЮБВИ» 16+
02.40 «ДЕНЬ СВЯТОГО ВАЛЕНТИНА» 16+
06.00 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА
05.25 «ДВА БОЙЦА» 12+
06.55 «НОЛЬ СЕДЬМОЙ» МЕНЯЕТ КУРС» 16+
09.00 «Новости недели» 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.40 «Легенды армии» 12+
11.30 «Моторы и колеса» 12+
12.20 «Война миров» 16+
13.10 «Код доступа» 12+
14.00 «Улика из прошлого» 16+
14.50 «Скрытые угрозы» 16+
15.40 «Секретные материалы» 16+
16.30 «Загадки века» 12+
17.20 «Специальный репортаж» 16+
18.00 Главное с Ольгой Беловой 16+
20.00 «Легенды советского сыска» 16+
22.35 «Москва фронту» 16+
23.00 «Фетисов» 12+
23.50 «АТАКА» 12+
01.40 «ЭКИПАЖ МАШИНЫ БОЕВОЙ» 12+
02.45 «ШЕЛ ЧЕТВЕРТЫЙ ГОД ВОЙНЫ…» 12+
04.10 «Часовые памяти» 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың төзелеш тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Камгэсэнергострой» капиталь төзелеш идарәсе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Петров** Альберт Николаевич **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары, намуслы хезмәте өчен Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе Түбән Кама шәһәре лицензия-рөхсәт бирү эше (Түбән Кама, Алабуга, Зәй, Менделеевск, Әгерҗе, Мамадыш һәм Сарман районнары буенча) бүлекчәсе фонд инспекторы **Сәлахова** Эльмира Вакыйф кызы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Салих Сәйдәшев исемендәге балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең вокал классы буенча укытучысы **Галиуллина** Гөлнара Илдар кызына, «Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәренең «Нардуган» җыр һәм бию ансамбле» муниципаль бюджет учреждениесенең вокалчы артисты (солисты) **Куканос** Гөлназ Әмирҗан кызына, Чаллы шәһәренең «Салих Сәйдәшев исемендәге 6 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль автоном өстәмә белем бирү учреждениесе укытучысы **Лобанова** Елена Витальевнага, «Ф.З. Яруллин исемендәге Әлмәт музыка көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе укытучысы **Петрова** Юлия Юрьевнага, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе укытучысы **Федотова** Рәмзия Фәрит кызына, «Арча балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү оешмасы укытучысы **Харисов** Рәдис Рафис улына, «Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе рәссамы-грим салучысы **Шаймарданова** Гөлфания Харис кызына **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасының «Кәләй урманчылыгы» дәүләт казна учреждениесенең Ракашево участок урманчылыгы участок урманчысы **Муханов** Иван Николаевичка **«Татарстан Республикасының атказанган урманчысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадыбаш урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Рәшитова** Фәния Харис кызына **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

Сәрия
МИФТАХОВА

ЭЗЕНӘ БАСЫП

«ВТ» ХӘБӘРЧЕСЕ КЫШКЫ УРМАНДА ҖӘНЛЕКЛӘР ХӘЛЕН БЕЛЕП КАЙТТЫ

Быел кыш салкын килде. Кар да күп яуды. Суыклар хайваннар дөньясына ничек тәэсир итте? Гомумән, урман кыш көне ничек яши? Без, карчанага утырып, Балтач урманына юл тоттык. Юл күрсәтүчеләребез – Арча урманчылыгының Балтач бүлекчәсе участок мастерлары Марсель Низаметдинов белән Тәүфыйк Камалов. Кышкы урман сулышын сезгә дә тәкъдим итәбез.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Бүре юкмы?

Җүләр! Бу суыкта урманда йөриләрмени, нәрсә калган сиңа анда? Салкын тияр, адашып калырсың һәм башкалар. Мине шулай туктатырга тырышсалар да, үз туксаным туксан иде. Барасы, күрәсе килә, бетте китте. Без сайлаган урманчылык та: «Юл юк, кар күп», – димәде. Карчанасын тапты, безне кеше аягы йөрмәгән сукмаклардан йөртте. 40 елдан артык эшләп, бер мәртәбә дә адашканнары юк икән. Димәк, без дә адашмабыз.

Бүредән курыксаң, урманга барма, ди халык. Куркып тормадык, шулай да «бүре» сүзе нигәдер авыздан беренче булып чыкты. Марсель Низаметдиновның алар белән күзгә-күз очрашканы бар икән. Берәү генә түгел, унлап җитмәсә. Йөрәге жу иткән. Машина тәрәзәсеннән керфекләренең ничек селкенүенә кадәр күргән хәтта. Техникада булгач, тимәгәннәр, билгеле. Ә бит ерткычларның зыян китергән чаклары да булмаган түгел. Узган гасырның сиксәненче еллар башында Чыпчык авылы фермасындагы 7–8 үгезне буып чыгып киткәннәр. Бик нык зыян сала башлагач, республикада аларга каршы көрәш чаралары күрелгән. Хәзер республикада берәү дә юк. Аюлар сирәк кенә күренгәли, кайчак умарта oларын тузгытып чыгып киткәлиләр икән. Әлеге участокта ике селәүсен исәпләнә. Кайчак аларның авылга барып, халыкны куркытканын да ишеткәләп торабыз. Аның каравы төлкесе, кабаны, пошие, сусары һәм башкасы бар.

Эзләр

Төпсез зәңгәр күк, ап-ак кар, биек агачлар һәм эзләр. Бар җирдә – тынлык. Тынлыкны бары тукран тавышы гына бүлгәләп ала. Урманда нинди хайваннар яшәвен эзләр күрсәтә.

– Күптән түгел генә пошилар йөреп узган. Монысы – селәүсен эзләре. Куяннарныкы да күренә. Бурсыклар хәзер йоклый, – дип, эзләр белән таныштырды безне белгечләр.

Хәзерге вакытта аучылар урманда җәнлекләрнең исәбен алалар. Бу эш 15 мартка кадәр дәвам итәчәк. Юлга чыкканчы, Татарстан Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетыннан кирәкле мәгълүматларны белешкән идек.

– Кышын ел саен хайваннарның баш санын алу бара. Бу чара ауның 19 төре буенча үткәрелә. Әлеге эштә комитет белгечләре, аучылар катнаша. Алынган мәгълүматлар аучылыкның торышын бәяләргә, республиканың җәнлекләр дөньясын саклау, торгызу чараларын күрергә мөмкинлек бирә, – диделәр безгә комитетта.

Исәп тәртибен Марсель абый яхшылап аңлатты. Аның сөйләвенчә, аучылар башта маршрут төзи. Аның яртысы – урман, яртысы – басу.

– Беренче көнне чаңгыда барып, бөтен булган эзләрне себерке белән бетерәсең. Икенче көнне шул юлдан кабат барырга туры килә. Кайсы хайванның кайсы якка китүен тамгалыйсың. Бер тәүлектә күпме йөргәненә игътибар итәләр. Эзләр саныннан баш санын исәпләп чыгаралар, – диде Марсель абый.

Республикада кайбер җәнлек һәм кошларның саны

Пошлар – **15700**, куян (беляк) – **9350**, куян (русак) – **33647**, тиен – **4315**, төлке –**5305**, затлы болан – **269**, селәүсен –**100**.

Урман тавыгы – **3453**, көртлек – **113938**, боҗыр – **6538**, соры кыр тавыгы – **151898**.

Поши, син кайда?

Урманны иңләп-буйлап йөреп тә, бер хайван да күрмичә кайтып булмый бит инде! Әйдәгез, табыйк! Урмандагы 50–60 пошиның берсен дә күрмәбезмени? Һич югы кабан очрар әле.

Башта без пошиларга тозлык куелган урыннарга бардык – күрмәдек. Аннан урманчылар алар еш очрый торган җиргә алып китте. Анда да юк. Аптырагач, кырга чыктык. Менә монда иңләп-буйлап йөргәннәр, карда ятып ял да иткәннәр. Тик безнең тавышны ишетеп качканнар, күрәсең.

– Аларга яшел печән салып куйсаң, ашамаячаклар. Хәзерге вакытта усак, тал кайрылары белән тукланалар. Сусарлар боҗыр белән тиенне ашый. Төлкеләргә – тычкан. Һәркайсының – үз ризыгы. Шуның белән табигатьтә тигезлек саклана, – ди Марсель абый.

Кар күп, азык аз булгач, Оренбургка таба китәләр икән, дип тә ишеткән бар. Әлеге сорауга да ачыклык керттек.

– Юк, китмиләр, барысы да – үзебезнекеләр, – дип елмайды Тәүфыйк Камалов. – Кар күп булгач, азык табу кыен. Агач кайрысын кимерүләре исә витамин җитмәүдән бит. Ризык эзләп, юлларга, авылларга чыгалар. Кызганыч, машина астына кергән чаклары да булгалый.

Поши эзләп, «Буран»ыбыз ауды, көрткә чумды. Кызганыч, берсен дә очрата алмадык. Кышкы урман сихри дә бит, әмма дөньяны бөтенләй онытып йөреп булмый, кайтасы бар.

Элмә – нәрсә ул?

Катнаш урман булгач, агачларның төрлесе үсә: ылыслысы, яфраклысы. Без инде ятрак агачларны күзәттек. Элмә шундыйларның берсе булып чыкты.

– Мин аны үзем дә карама белән буташтырам, – диде Марсель абый. – Алар охшаган. Бары яфраклары гына бераз аерыла. Элмәдән элек көянтә бөккәннәр, дуга ясаганнар.

Кызык, агачның гомере күпме икән?

– 81 яшьтән соң – ылыслы, 61дән соң яфраклы агачлар киселергә тиеш. Артыгын үссә, картая, чери башлый. Агач өлгергәнче – кислород, картайгач, углекислый газ бүлеп чыгара. Халык кайчак, урманны кисәләр, бетерәләр, дигән сәер сүзләр дә әйткәли. Юк, килешмим. Агач кисүнең – үз тәртибе. Картайганын кисмәсәң, алар авыру тарата башларга мөмкин.

БЕЛГЕЧ СҮЗЕ

Федор БАТКОВ, Татарстан Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты җитәкчесе:

– Кар күп яву урман хайваннарының хәрәкәтләнүен кимегә, ә юеш кар авырулар таралуга китерә. Суыкларда аларның активлыгы түбәнәя. Кошларның кайберләре суыкларны кичерә алмый. Әле ярый аларны ашатучы битараф булмаган кешеләр бар. Тояклылар, азык эзләп, ылыслы урманнарга китә. Без бу вакытта аучылардан җимнәрне күбрәк әзерләүне сорыйбыз.

Әй, сез, кошкайлар!

Урманда тукраннар, кыр тавыклары, боҗырлар, бытбылдыкларны күрергә мөмкин. Әйе, бытбылдык. Баксаң, аны өйдә генә асрамыйлар. Чаңгы белән барганда, кыр тавыклары, боҗырлар курыкмыйча карда йоклап ята икән. Шул вакытта алар кардан дәррәү килеп өскә күтәрелә. Менә шулай куркыта торган гадәтләре дә бар икән. Кошлар исә каен алкалары белән туклана.

– Соңгы вакытта басуларда шактый зур кошлар – ак койрыклы бөркетләр күренә башлады. Бервакыт төлкене эләктереп, шуны ашап маташа иде. Янына килсәң, күзеңне чукып та чыгарырга мөмкин. Нәрсә селкенә, шуны чукый ул, – диде Марсель абый.

Намус эше

Урманга барып ял итү генә рәхәт. Ә менә эшкә бару бөтенләй икенче. Җәен эссе, дөнья чебен-черки белән тулган. Көз көне яңгыр, кышын суык. Менә шул авырлыкка түзсәң генә урман сине үзенә кабул итәчәк. Белгечләр шулай ди.

– Агачларны саныйбыз, үлчәмнәрен алабыз. Барысын да язып куябыз. Барлык диләнкедән кубометрны чыгарабыз, – ди Тәүфыйк абый.

Сүзгә Марсель абый кушылып: «Урманга бардыңмы?» – дип, берәү дә көн саен эшебезне тикшереп тормый. Монысы – намус эше. Безнең маршрутлар билгеле. Көн саен шуны узабыз. Кайчак җәяүләп 15әр чакрым йөрибез. Төп эшебез – урманны саклау», – диде.

Урманның киләчәге бар, дип ышандырды белгечләр. Картайганын кисеп, яшьләрен утыртып, тәрбияләп торалар чөнки. Кеше урманнан ерагайса да, ял итәргә, ара-тирә коры-сары кисәргә килгәли.

ЕГЕТЛЕК

ӘФГАНЧЫЛАР ЯРДӘМГӘ АШЫГА



Бу көнне без, гадәттә, Әфганстанда хезмәт итеп кайткан якташларыбыз белән ел саен диярлек истәлекләр барлап алабыз. Бу юлы да шулай булды. Тарихны үзгәртеп булмый, әлбәттә, әмма егетләр шактый үзгәрде, дип әйтергә кирәк. Элек күбрәк сүз әфганчылар мәнфәгатен кайгырткан законнарның эшләнеп бетмәве, тиешле ярдәм күрсәтелмәве тирәсендә әйләнсә, бүген инде алар өчен төп вакыйга – махсус хәрби операция. Әфганчылар хәзер үзләре ярдәмгә ашыга. Бүген сүзебез шул хакта.

Фәнис ЗӘЙНУЛЛИН,
Хәрби хәрәкәтләр ветераннарының Апас районы буенча координация советы җитәкчесе

«Чын егетләр зарлануны белми»

– Хезмәткә алынгач та, мине чик сакчылары гаскәренә билгеләделәр. Ил чикләрен сакларга әзерлибез, дисәләр дә, Әфганстанга керәсебезне алдан ук белдек. Өч ай өйрәнүләр үткәч, яшерен мандат комиссиясе төзеп, сөйләшүләр үткәреп, сайлап кына алдылар, теләмәгән кешене мәҗбүр итмәделәр.

Интернет челтәрләрендә бүгенгә кадәр, бу сугыш кирәк идеме, дигән сорауга җавап эзлиләр. Без, Әфганстанда кан койган егетләр, кирәк иде, дип саныйбыз. Без илебезнең чикләрен сакладык. Моның белән горурланабыз. Әгәр дә бу илгә америкалылар алданрак керсә, аларның Советлар Союзына һөҗүм итү куркынычы бик зур иде. Ахыры ни булып бетәр иде, кем белә? Хәзер махсус хәрби операциядә катнашучы егетләргә карыйм да шул чакларны искә төшерәм. Без дә нәкъ шулай үзебез сипләгән окопларда, землянкаларда яшәдек. Тауларга киткәндә йокы капчыкларын, корал, өч көнлек азык-төлекне үзебез белән ала идек. Кыш көннәрендә бик салкын булды, ә җәй көннәрендә артык эсселектән интектек. Өстәвенә еланнар, төрле агулы бөҗәкләрдән сакланырга кирәк, малярия, сары авырулары теңкәгә тия… Төннәрен тауларга засадага чыгып китә идек. Вертолеттан тау башларына төшерәләр иде безне. Дошманнар да ата, без дә атабыз. Егетләр яраланса, бигрәк тә һәлак булса, йөрәк әрнүгә чик-чама юк. Аннары шул ук вертолетлар ярдәмгә дә киләләр иде. Әфганстанның гади халкы совет солдатын ярата, үз күрә иде. Без банда төркемнәренә каршы көрәштек.

1983 елда бик авырга туры килде. Безне Пакъстан чигенә җибәрергә тиешләр иде. Әмма ни өчендер чикне ачтылар һәм бу илдән банда төркемнәре иркекле төстә корал ташый башлады, Әфганстан территориясенә наемниклар керде. Михаил Горбачев хакимияткә килгәч, безнең өчен «үтергеч» тагын бер яңалык өстәлде. Корал тоткан берәр әфганлы килә икән, аңа атмаска дигән карар иде бу. Имеш, үзе ата башласа гына каршылык күрсәтергә ярый. Соң, ул беренче булып миңа төбәп аткач, аңа ничек каршылык күрсәтә алам инде? Хәтта шундый хәлләр дә булды: дошман безгә карый-карый масаеп кына үтеп китә дә, берәр әйбер артына качып, якыннан гына ут ача. Кыскасы, баш күтәрергә дә ирек бирми башладылар. Хәтта күпне күргән офицерлар да аптырап калдылар. Мин әлегә кадәр бу хәлләрне аңлый да, кабул итә дә алмыйм.

Армиядән кайткач, район комсомол комитетында эшли башладым. Әфганстанда безнең җирлектән 6 кеше һәлак булган иде. Бервакыт шулай барысының да хәлен белешеп, сөйләшеп чыгарга булдым. Авыл кешеләре бит инде. Кайсының утыны юк, кайсының печәне дигәндәй… Мин шунда гына балалары һәлак булган әти-әниләрнең ничек бетерешкәнен күрдем. Аларга безгә караганда да кыенрак булмадымы икән әле?! Сугыш кырында чагында бу хакта башыбызга да кереп карамаган. Шул гаиләләргә ярдәм итәргә алындым. Йөри торгач, мине үз уллары кебек кабул итә башладылар.

Үзе окопта яткан кеше бүгенге хәлләрне дә бик яхшы аңлый. Махсус хәрби операциядә хезмәт итүчеләргә ярдәм итү өчен дәррәү күтәрелделәр. Хәрби конфликтларда хезмәт итүчеләргә аена 3 мең сум компенсация бирәләр. Шуның бер меңен махсус картага күчереп барабыз. Апаста хәрби операциягә ярдәм итү эшен хакимият алып бара. Халык җибәрәсе әйберләрен «Алга» дип аталган балалар һәм үсмерләр клубына китерә. Сугыш ветераннары бик актив эшли. Беркем дә каршы килми. Дөрес, баштагы мәлдә, безгә гуманитар ярдәм килмәде бит әле, диючеләр булгалаган иде. Анда бит бернәрсә дә кертергә ярамады. Шуңа ниндидер дәгъва белдереп булмый. Хәзер андый сөйләшүләр юк инде. Заманында әфганчыларга үзебез дә ярдәм итәргә тырыштык. Администрация ярдәме белән 12 кешене фатирлы иттек. Берничә әфганчының уллары хәрби операциядә хезмәт итә. Аларның хәлләрен бигрәк тә белешеп торабыз.

Хәлләрне белешеп торабыз дигәннән, егетләргә психологик ярдәм күрсәтү бик кирәк ул. Чөнки заманында без үзебез бик авыр хәлдә калган идек. Организмны бик тузгыдырып кайттык. Үземнең дә кызып китә торган гадәтем бар иде. Стресслар да бик яман булды. Ә вакытында ярдәм кулы сузучы булмады. Шуңа күрә Чечня сугышыннан кайтканнарны шундук үз кулыбызга алдык: күбесен тернәкләндерү курсларына җибәрдек. Бүген хәрби операцияләрдән кайтучылар белән дә шул ук хәл. Очрашканда да, кәефләре төшмәсен дип, кешеп кенә аралашабыз. «Башта уйлап бетерегез, аннары гына сөйләгез», – дип киңәшләр бирәбез. 15 февральдә тагын бер кат очрашып алырга исәп. Хәрби операциядән кайтучылар да дәшми-тынмый гына авылларында яшәп яталар. Чын егетләр зарлануны белми инде ул. Әмма күз-колак булу кирәк.

Рөстәм ШӘЙХЕТДИНОВ,
«Әфганстан һәм башка локаль сугыш инвалидларының Татарстан иҗтимагый оешмасы»нда Әлки районы бүлеге җитәкчесе

«Безне берни дә куркытмый»

– Мин армиягә үзем теләп киттем. Әнием укытучы булып эшли иде. Бер генә бала булганга, калу мөмкинлегем дә бар иде. Тик хезмәт итәргә дә бармыйча, «яраксыз»га чыгып ятуымны күз алдына да китерә алмадым. Хәрби комиссариатка бардым, сөйләштем, повесткаларны кулыма тоттырып җибәрделәр. Егерме көн тирәсе өйрәнүләр үткәч, туган илгә тугрылыклы булырга ант бирдек тә Әфганстанга кердек. Мин 201 нче дивизиягә эләктем. Батальонда 500ләп машина бар иде. Совет гаскәрләрен матди яктан тәэмин итү белән шөгыльләндек, ягъни мәсәлән, безнекеләр кайда урнашкан, шунда азык-төлек, корал, ягулык ташыдык. Бигрәк тә Пакъстан чигендәге таулы юлларда бик авыр булды. Анда бит һәркайда сиздермәстән генә дошман каршы ала. Тормыш гел кыл өстендә. Ике ел хезмәт итү чорында төрлесен күрергә туры килде инде. Бик күп егетләрне югалттык. Иң авыры шул булгандыр, мөгаен. Чираттагы командировкага чыгып киткән саен без кемнең дә булса исән кайтмасын күңелебез белән тоя идек. Әмма бер-беребезгә берни сиздермәскә тырышабыз. Көлешкән-шаярышкан булабыз. Язмышыңа шулай язылса, шундый мәхшәрдә дә исән каласың икән.

Кайткач, югары белем алырга дип укырга кердем. Аңа хәтле техникум тәмамлаган идем. Эшләп укырга туры килде. Үзем кебек Әфганстанда хезмәт иткән 58 егет белән бригада төзедек. Шуңа җитәкчелек иттем. Ярдәмләшеп яшәдек. Эшләгән акчабызны бүлеп, мохтаҗ гаиләләргә дә тараттык. Зур сынаулар бердәм булырга өйрәтте. Менә нинди сыйфат яшәтә безне.

Хәзер мин махсус хәрби операциядә хезмәт итүче егетләребез янына йөри башладым. Егерме тапкыр барып кайттым инде. Кайчагында бездән: «Куркыныч түгелме?» – дип сорыйлар. Без бит сугыш юлын үткән егетләр, берни дә куркытмый. Бару-кайтуы 6 мең чакрым юл җыела. Кайда Татарстан егетләре, шунда барырга тырышам. Хәрби операциядә Әлки районыннан 90га якын егет мобилизацияләнгән. Без алар янына Казандагы танк полигонында чакта ук барып йөргән идек. Аннары – Ростовка, хәзер инде – «кайнар нокта»ларга. Азык-төлек, кием, тепловизор, рацияләр алып барабыз. Март ахырында тагын барырга җыенабыз. Кирәк әйберләрне егетләр үзләре сорый. Ялга кайтучылар да бар. Аларны күтәренке рух белән каршы алабыз, озатып калабыз.

Минемчә, локаль сугышларда катнашучылар, шул исәптән әфганчылар да, буыннар чылбырын дәвам итә кебек. Чөнки Бөек Ватан сугышы батырлары инде бармак белән санарлык кына калып бара. Ә ут эченә киткәндә, үлем белән күзгә-күз очрашкан кешеләр белән утырып сөйләшү үзе үк ярдәм итә. Мин районда Юнармия штабын да җитәклим, яшьләрне патриотик рухта тәрбияләү бик кирәк. Бу – бик яхшы хәрәкәт. Башка әйберләр уйлап тапканчы, шуны үстерергә генә кирәк дип уйлыйм.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Сан

Әфганстандагы хәрби хәрәкәтләр барышында Татарстанда туып-үскән яки яшәгән

- **296** кеше һәлак була;
- **231** кеше сугышта алынган яралардан яки көчле психологик тетрәнүләрдән үлә;
- **546** кеше төрле имгәнүләр ала, **311** кеше инвалид булып кала.

НИКОЛАЙ ТИТОВ:

«АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫНДА БАР ҺӨНӘР ПОПУЛЯР»

Башка бик күп тармаклар шикелле үк, авыл хуҗалыгы да бер урында гына тормый. Белгечләргә дә, эшчеләргә дә үзгәрешләр, яңа алымнар белән бер аяктан атларга туры килә. Шуңа күрә республикада аларны кабаттан укыту, белем бирүгә зур игътибар бирелә. Татарстанның агробизнес кадрларын кабаттан әзерләү институты ректоры Николай ТИТОВ белән укытуда яңа алымнар һәм популяр юнәлешләр турында сөйләштек.

:: Николай Леонидович, авыл хуҗалыгы тармагына да яңа таләпләр куела, яңа һөнәрләр һәм белгечләр кирәклеге ачыклана. Соңгы елларда республикада нинди яңа юнәлешләр барлыкка килә?

– Соңгы елларда җиләк-җимеш үстерү һәм балыкчылык белән шөгыльләнергә теләүчеләр саны артты. Инде дүртенче ел без үзебезнең курсларда бу юнәлеш буенча укытабыз. Татарстанда беренче ел элек Аквакультура һәм умартачылык идарәсе бетерелгәч, әлеге юнәлеш игътибардан читтәрәк калган иде. Ә белем алырга теләүчеләр бар, чөнки болар – безнең республика өчен чагыштырмача яңа һәм кызыклы юнәлешләр. Моннан тыш, хәзер хуҗалык итүнең эре формаларына игътибар күбрәк бирелә. Чөнки терлекчелектә авыл хуҗалыгы продукциясен аз күләмдә җитештереп, зур табыш алу бик авыр. Мондый шартларда ничек дөрес эшләргә? Курсларда бу турыда да мәгълүматлар бирәбез.

:: Ә хәзер агробизнеста нинди һөнәрләр аеруча популяр?

– Чын күңелдән ышанып әйтә алам: барысы да! Инженерлар, сыер савучылар, механиклар, бухгалтерлар, икътисадчылар, зоотехниклар, ветеринарлар, агрономнар... Бары тик аларның эш алымнары гына үзгәрә, тармакка яңа технологияләр үтеп керә, электроника, цифрлаштыру тамыр җәя. Элек без һәр үзгәрешне яңалык буларак кабул итә идек, ә хәзер алардан башка эшләп булмавына төшендек. Бүген авыл хуҗалыгына яңа форматтагы белгечләр кирәк. Бу чаралар белгечләр өчен генә түгел, ә төгәл, оператив карарлар кабул итәр өчен җитәкчелеккә дә уңайлы. Хәзер теләсә нинди эре холдинг җитәкчесе белән сөйләшсәк тә, алар белгечләрне яки үзләре үстерү, яки икенче оешмадан зуррак хезмәт хакына кызыктырып, сатып алу яклы булуын әйтә. Ә авыл хуҗалыгында эш теләсә нинди юнәлештә дә күп. Халык арасында: «Агроном җәен эшли дә кышын ял итә», – дигән фикер йөрсә дә, кышын ял итүче агроном юк ул. Аларның эше ел әйләнәсе дәвам итә. Климат та үзгәрә. Соңгы елларда корылык белән сыналабыз, узган ел терлек азыгын әзерләү белән проблемалар булды.

:: Институт галимнәре уздырган курсларда кемнәр белемнәрен чарлый ала?

– Үзләренең хезмәткәрләрен агрохолдинглар да җибәрә, фермерлар, аерым кешеләр дә килә. Бигрәк тә умартачылар актив. Шушы көннәрдә без алар өчен курслар башлап җибәрдек. Ел саен 50дән артык кешене укытабыз. Умартачылык – бик кызыклы, үзенчәлекле юнәлеш. Хәзер алар өчен дә таләпләр артты. Быел һәр умарта оясы ветеринария хезмәте аша идентификация узарга тиеш, паспортлары булу кирәк. Бу аларга килачәктә компенсация алу өчен дә мөһим. Әйтик, узган ел безнең белгечләр, галимнәр Арча районы умартачысы Нурулла Закировка һәлак булган бал кортлары өчен акча алырга ярдәм итте. Гомумән алганда, без утызлап юнәлеш буенча кабаттан укытабыз: икътисад, үсемлекчелек, терлекчелек, дәүләт заказлары, идарә итү һәм башкалар. Моннан тыш, һәр тармак тагын төрле юнәлешләргә бүленә: әйтик, үсемлекчелектә ашлык, терлек азыгы культураларын үстерүдә яңа технологияләр, экологик яктан чиста продукт җитештерү өйрәнелә. Терлекчелектә ветеринарлар өчен яңа мал авырулары, аларны дәвалау ысуллары турында сөйлибез. Барлык төр юнәлешләр буенча да районнарга чыгып, практик күнекмәләр алырга тырышабыз. Авыл хуҗалыгында да, башка бик күп өлкәләрдә кебек үк, яңалык күп. Шуңа күрә бу укулар һәр белгечкә кирәк.

:: Курсларда кайсы аралыкта укырга мөмкин?

– Кайбер программалар ел әйләнәсе бара, кайбер юнәлешләр буенча аерым бер айларда гына укырга мөмкин. Үзенең җитештерү оешмасын ачып җибәрергә теләүчеләр дә килә безгә. Моннан тыш, курслар Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы бәйгеләрендә катнашучылар өчен дә файдалы.

:: Ничек уйлыйсыз, кешегә кайсы авыррак: кабаттан укумы, әллә яңа һөнәр үзләштерүме?

– Без беренче чиратта белгечнең югары һәм урта махсус уку йортында алган база белеменә таянабыз. Ә инде бакчачылык белән шөгыльләнергә теләге икән инде, аның барыбер ниндидер нигезле белеме булырга тиеш. Әгәр кешенең профильле югары белеме юк, ләкин ул теге яки бу юнәлеш буенча укырга теләге икән, югары белем базасы нигезендә укытып, таныклык бирергә хокукыбыз бар. Ә югары белеме булмаган кешегә бары тик сертификат кына бирелә.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ФГБОУ ДПО «Татарский институт переподготовки кадров агробизнеса» объявляет набор слушателей на обучение на безвозмездной основе по нижеуказанным дополнительным профессиональным программам повышения квалификации и профессиональной переподготовке.

Месяц	Срок проведения	Наименование программы	Вид обучения	Кол-во часов	Кол-во чел.	Категория слушателей
В течение года	22.01 – 15.12	Агрономия	Профессиональная переподготовка	504	20	Агрономы
	22.01 – 15.12	Государственное и муниципальное управление	Профессиональная переподготовка	537	25	Государственные и муниципальные служащие
	22.01 – 15.12	Менеджмент в организации	Профессиональная переподготовка	504	20	Менеджеры
	22.01 – 15.12	Организация ведения пчеловодства	Профессиональная переподготовка	504	20	Пчеловоды
	22.01 – 15.12	Управление персоналом	Профессиональная переподготовка	501	25	Специалисты кадровых служб
	22.01 – 15.12	Бухгалтерский учет	Профессиональная переподготовка	601	10	Бухгалтера
Февраль	01.02 – 14.02	Организация воспроизводства сельскохозяйственных животных	Повышение квалификации	72	25	Техники-технологи, осеменаторы, зоотехники, ветврачи
	06.02 – 16.02	Эффективное ведение агробизнеса в условиях малых форм хозяйствования	Повышение квалификации	72	35	Фермеры
	05.02 – 16.02	Прогрессивные технологии в АПК	Повышение квалификации	72	43	Агрономы
	12.02 – 22.02	Повышение эффективности развития пчеловодства	Повышение квалификации	72	60	Пчеловоды
	19.02 – 01.03	Организация труда в растениеводстве	Повышение квалификации	72	43	Агрономы
	26.02 – 07.03	Основы противодействия коррупции	Повышение квалификации	72	30	Руководители, специалисты предприятий АПК
Март	11.03 – 22.03	Этика и психология управленческого труда	Повышение квалификации	72	34	Руководители, специалисты предприятий АПК
	25.03 – 05.03	Управление и развитие сельских территорий	Повышение квалификации	72	30	Государственные и муниципальные служащие
	25.03 – 05.03	Повышение эффективности отрасли животноводства	Повышение квалификации	72	40	Зооветспециалисты
Апрель	15.04 – 26.04	Управление персоналом	Повышение квалификации	72	40	Специалисты кадровых служб
Июнь	13.06 – 23.06	Экономика и управление на предприятиях АПК	Повышение квалификации	72	43	Экономисты, бухгалтера
Октябрь	30.10 – 10.11	Основы производства и сертификации органической сельскохозяйственной продукции	Повышение квалификации	72	20	Руководители, специалисты предприятий АПК
Ноябрь	1.11 – 15.11	Повышение эффективности предприятий АПК	Повышение квалификации	72	43	Руководители, специалисты предприятий АПК
	11.11 – 22.11	Цифровая трансформация по отраслям АПК	Повышение квалификации	72	20	Руководители, специалисты предприятий АПК
	18.11 – 29.11	Повышение эффективности ветеринарных мероприятий	Повышение квалификации	72	43	Зооветспециалисты

С подробной информацией можно ознакомиться www.tipkadpo.ru на официальном сайте института, а также по тел.: Приемная: (843) 277-51-86. Учебная часть: (843) 277-81-67.

Реклама хокукында

АЙГӨЛ КЫЯМОВА:
«ӘТИ ҖЫРЛАРЫНДА ЯШИ»

«Сылукай», «Әниемә», «Сине көтәм» («Кил син»). Татарстанның атказанган артисты Әлфис Кыямовны халыкка таныткан җырларны саный китсәң, шактый алар. Әмма бүген дә телдән төшмәгәне – «Кил син»дер, мөгаен. Шушы көннәрдә моңлы җырчының вафатына 20 ел булган икән инде.



Кызы, Татарстанның атказанган артисты Айгөл КЫЯМОВА белән истәлекләрне барладык, шәхес кадере турында сөйләштек.

:: Айгөл, бу көннәр сезнең өчен моңсу көннәрдер. Егерме ел элек әтиегез Әлфис Кыямов бакыйлыкка күчкән... Ул нинди әти иде?

– Әти минем өчен идеаль ир үрнәге булды. Хатын-кызга, олыларга игътибарлы, кайгыртучан, итагатьле иде. Кешеләр белән аралашканда шаян, шук кебек тоелса да, тормышта ул җитди, күп сөйләшми. Без аны күз карашыннан аңлый идек. Мин әтине гел сагынып, зарыгып яшәдем. Еш кына айлар буена сузылган гастрольләргә чыгып китә, аннан зур шатлык булып, куян күчтәнәчләрен күтәреп кайтып керә. Инде хәзер үзем дә әни булсам да, гел сагынам, зарыгам. Гәрчә кайтып кермәячәген аңласам да. Күңелдә балачакта ук яралган «әти кирәк» дигән хис һаман бар әле.

Егерме ел элек әтисез калсак та, ул әле кичә генә булган хәл кебек. Ул вакытта миңа – 16, энекәшкә 5 яшь иде. Инде ул да хәзер әти.

Безнең әти 8 февральдә вафат булды. Шул көнне кич, нәкъ быелгы кебек, буран чыкты. Иртән Мәдәният министрлыгы безгә автобус бирде. Шул автобуска әтинең җәсәден урнаштырып, әни, мин, министрлык вәкилләре белән Башкортстанга, әти туып-үскән Борай районының Бакалы авылына кузгалдык. Бер караганда, Казан – Борай арасы 5–6 сәгатьлек юл инде ул. Ә без буранда адашып, әтинең мәңгелек йортына тәүлек буе кайттык. 10 февральдә әтине гүргә иңдердек. Ул чалт аяз көн булды. Гаҗәп инде, быел да истәлекләрне яңартып, һава торышы кабатланды.

Гадәттәгечә, рухы шат булсын дип, Казанда аш үткәреп алдык. Җаен Бакалы авылына кайтырбыз дип ниятләп куйдык.

:: Әлфис абыйның туган нигезе исәнме?

– Авылдагы йорт, шөкер, нык. Әтинең туганнары исән-сау, бертуган апасы Борайда яши, абыйсы Финат төп йортта тора. Әти туып-үскән йортка «Бу йортта Татарстанның атказанган артисты Әлфис Кыямов туып-үскән» дигән истәлек тактасы да урнаштырылган. Бакалы – нык авыл, әмма ул да картая инде. Әле күптән түгел генә өлкәннәр, Бакалыда да бер урам бетте, дип искә алдылар.

:: Ничек уйлыйсың, халык хәтерлиме Әлфис Кыямов дигән җырчыны? Бездә шәхес кадере ни дәрәҗәдә?

– Әтине хәтерлиләр, аның җырларын сорап язалар. Мин, бәлкем, социаль челтәрләрдә аның җырларын, видеоинтервьюларын урнаштырмас та идем, әмма халык сорый. Видеолар астына үзләренең истәлекләрен язып калдыралар, безнең авылга килгән иде, сагынабыз, дип язалар, күбрәк урнаштыр әле, дип үтенечләрен җиткерәләр. «Каян тыңлап була Әлфис Кыямов җырларын?» – дип сораучылар да күп. Мин шушындый көннәрдә булса да җырларын, интервьюларын интернетка чыгарам инде. Әти җырларында яши.

:: Әлфис абый бер интервьюсында: «Заводка китәм, эстрадада йөреп, гаилә туйдырырлык та эшләп булмый», – дип әйткән. Эстрада бүлегенең таркалуы, артистларның кирәксез булып калуы да аның язмышына тәэсир итми калмагандыр.

– Ул шундый чорга туры килгән: эстрада бүлеге таркалган, идеология беткән, мәдәният һәм сәнгать әһелләре кирәксез булып калган. Мөгаен, ул елларда бик күп шәхесләр төшенкелеккә бирелгәндер. Аннан килеп, һәрбер артист, нинди генә чорга туры килмәсен, менә шушындый хәлгә килә ала. Чөнки иҗат кешесе ул – хис кешесе. Айлар буе гастрольләрдә йөреп тә, бәлкем, теләгән суммасын алып кайта алмагандыр. Бәлки, башка сәбәпләре дә булгандыр.

> Әти тырыш, эзләнүчән кеше иде. Һәм ул балкып чыгарлык үз җырын тапты. Нәкъ менә шул җырдан соң аның бәхетләй икенче тормышы башланды.

:: Чыннан да, Әлфис Кыямов, дигәч, күпләр «Кил син» дигән җырны искә төшерәдер.

– Әйе, бу – Алмаз Хәмзин сүзләренә язылган «Сине көтәм» дигән җыр. Аны хәзерге башкаручылар «Кил син» дип йөртә башлады. Әти бу җырны да кассетага яздырып алып кайтты һәм без аны гаилә белән җыелышып тыңладык. Әти җырга, башкаруга бик таләпчән булды. Аңа һәр сүзнең аңлаешлы, ачык әйтелүе мөһим иде. Ул без яңа җырны тыңлаганда да, монысы аңлашыламы, дип кат-кат сорый иде. Әйтергә кирәк, җыр гаилә советын уңышлы узды. Халык күңеленә дә юлны тиз тапты. Ахыр чиктә, әти концертны шушы җыр белән башлап, шуның белән тәмамлый иде. Халык сорый иде чөнки. Бу җыр безгә бик кадерле, чөнки әни аның клибында да төште. Хәзер дә съемка вакытларын елмаеп искә ала.

:: Аның җырларын башкалар җырлауга сез нинди караштa?

– Әтинең җырлары яшәгәнгә, җырчыларның аларны башкаруына мин бик шат. Аларның «бу җыр – Әлфис Кыямов репертуарыннан» яки «Әлфис Кыямов истәлегенә» дип искәртүләре күңелгә сары май булып ята. Башкарырга рөхсәт сорап та шалтыраталар. Аңа бик күңел була инде. Ә бар шундый җырчылар: алар болай искәртүне кирәк санамый, бер яңа җыр итеп тәкъдим итә. Бу күңелне әрнетә инде.

:: Әлфис Кыямов дигән җырчыны хәтерләсеннәр өчен дәүләт дәрәҗәсендә нәрсә эшләргә кирәк?

– Бездә шәхесләр бик күп. Әмма мин, безнең әтине дәүләт дәрәҗәсендә күтәрсеннәр дип, лозунглар кычкырып йөри торган кеше түгел. Без андый тәрбия алмаган. Әти барысына да үз хезмәте белән иреште. Вафат булган айда аңа «Татарстанның атказанган артисты» дигән исем бирелде. Әгәр исән булса, бәлкем, әле халык артисты исеменә дә лаек булган булыр иде. Ә без – гаиләсе кулдан килгәнне эшләргә тырышабыз. Юбилей елларында үз көчебез белән искә алу кичәләрен оештырдык. Интернетка җырларын урнаштырырга тырышам. Аның җырлары радио-телевидениедә күбрәк яңгыраса, сөенер идем дә бит... Истәлек китабы туплау дигән ниятебез дә бар.

Туган ягында әтигә хөрмәт зур. Моңа бик сөенәбез. Яшәгән йортына истәлек тактасын кую – бик зур хөрмәт билгесе. Әти Борай районында укыткан да әле, бәлки, мәктәпкә аның исемен бирерләр, кем белә...

:: Биюче һөнәрен сайлавыңа әтиеңнең тәэсире булдымы?

– Гаиләбез белән сәнгатьтә кайнаганга, минем әлеге юлны сайлавым табигый булгандыр. Әти-әни сәләтемне кечкенәдән күреп алды, миңа зур таяныч булдылар. Безнең гаилә барысына да үз тырышлыгың белән ирешергә кирәк дигән кагыйдә буенча яшәде. Ә инде минем бию белән тәмам җенләнүемне аңлагач, әти, кызым, әгәр шушы юнәлешне сайлыйсың икән, укырга, һөнәрне профессиональ дәрәҗәдә үзләштерергә кирәк, диде. Шулай итеп мин аның хәер-фатихасында Казан хореография училищесына укырга кердем. Шушы киңәше өчен әтигә мин гомер буе рәхмәтле.

:: Бию – сәнгатьнең иң авыр төре, дип әйтсәк тә ялгыш булмас. Ә биеп тормыш алып барып буламы соң?

– Әтинең ашында да бу турыда сүз булган иде. Рамил хәзрәт Юныс: «Бала карында чакта ук Аллаһы Тәгалә аңа сәләт бирә. Менә шул сәләтне син тормышта дөрес итеп кулланырга тиеш. Шулай булганда ул сиңа төрле яктан бәрәкәт китерер», – дигән иде. Чынлыкта да шулай бит. Мин биюдән ләззәт алам һәм аның нәтиҗәсен дә күрәм. Бию миңа авыр йөк түгел, ул – минем яраткан эшем. Әйе, ул миллионнар китерми, әмма мин бәхетле. Үзем эшләгән Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблен яратам. Аларның концертларын кечкенәдән карый һәм шунда эшләячәгемне сизенә идем.

– Бездә биюгә караш нинди?

– Мин бу хакта уйланам һәм сәнгатьнең ниндидер төренең алга чыгуын халыкның үзенчәлегенә бәйледер дип уйлыйм. Әйтик, безнең халыкка җыр сәнгате якынрак кебек, ә башкортларда – бию. Дөрес, соңгы вакытта бездә дә бию күтәрелеп китте. Бик күп җирләргә бию буенча мастер-класслар үткәрергә чакыралар, хәтта чит илләрдә дә татар биюе буенча дәресләр биргән булды. Казанда «Хәрәкәттә – бәрәкәт» проекты башланып китте. Ул да халыкны уятып җибәрде. Тамашачы һәр җирлекнең үз биюе барлыгына, аның тарихка бәйле булуына төшенде. Һәр хәрәкәтнең үзенең мәгънәсе бар һәм бу – бик кызык. Беләсезме, биюне тагын ничек күтәреп була? Телевидениедән татар биюен күбрәк күрсәтсәләр, балалар милли биюгә күбрәк тартылыр иде. Әлегә алар башка биюләр тәэсирендә.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

АЙЗИРӘК ГӘРӘЕВА-АКЧУРА

(ХИКӘЯ)

КУЕНЫҢДА НИ БАР?

<Дәвамы. Башы 29 гыйнвар, 2, 9 февраль саннарында

Салих аның акрын гына кеткелдәвенә кушылып көлде. Аннары:

– Мөнир абый, әнә теге урамда, – кулын сузып, мәчетнең уң тарафындагы тар урамнарга күрсәтте, – ике кибете бар иде. Көнбагыш, коры җимеш сата иде. Без бала-чакта йөри идек. Әллә кем абзый...

– Гайфулламы? Бер күзе кысык булганга Кысык күз дип йөрттеләр аны.

– Әйе, әйе! Шуның торыны өйләнә, ди. Бу атна соңында туй ясыйлар. Авылдан бөтен кешене чакырган. Син дә кил, Мөнир абый!

– Кайда була икән соң?

– Шәһәр паркында, яңа ачылган ресторанда.

– Ерак икән, анда ук барып җитеп булмас. Картайдык инде...

– Ни картаю! Авылдагы 90 яшьлек Нәзифә апа әйткәндәй, туйдан тукмак та калмый. Үзе дә йөреп тора, машалла.

Илнур боларның гәпләшүен башта тыныч кына күзәтте. Аннары уйга калды. Кем үлгән, кем өйләнә – берсен белми, нигә кирәк болар?! Картлар үткәненә тотынган, яшьләр – киләчәккә. Китәргә, таныш түгел шәһәр урамнарында адашырга. Адашу халәте мажарасын татырга. Әнә карт ничәнче мәртәбә инде куенын капшап куйды, эсседә, кояш астында утырганчы, өенә кайтса әйбәтрәк тә соң... Ярый, беренче булып үзенә китәргә кирәк.

– Мөсәгыйтегез олса, качтым, – дип, янә төрекчә саубуллашты. Аны карт татарча:

– Киләсе җомгада күрешербез, – дип озатты.

Мосафир «ачык йөз сәдакасы»н елмаю аша мулдан өләште дә юкка чыкты.

Карт, өенә кайткач, пөхтә итеп җыештырылган бүлмәсенең тәрәзәсен ачып куйды, өс-башын алыштырды. Ачык тәрәзәдән озын-озак итеп сузылган азан тавышы яңгырап керде, карт акрын гына икенде намазына әзерләнергә керешә, тәһарәт алырга юнәлде. Намазын кылып бетергәч тә утырган урындыгыннан торырга ашыкмады. Бераз дисбе төймәләрен чикте, аннары өстәлгә куйган китабына үрелде. Һәм укуын дәвам итте.

«Карачабәй җирләренә килеп җиттек. Казан татар мөһаҗирләрен урнаштыру турындагы рәсми кәгазь эшләре тәмамлангач, җирләрне күрсәттеләр. Җир дип өмет иткәнебез сазлык икән, черкиләр шул сазлык өстендә кара болыт кеби. Чарасызлыктан башыбызга килгәннәрдән, озак-озын юл газапларыннан тәмам йончып беттек. Тегеләй уйладык, болай уйладык, яшәмәле җир түгел.

Юлга әллә никадәр масраф чыкты, мәмләкәттән китергәннәр бетте. Бездән алда килгән татарлар киңәше белән, кире Бурсага килдек, солтаннан ярдәм сорап яздык. Бездән күпме кеше килгәнне белештеләр. Уналты кеше булуыбызны җиткердек. Шуннан соң унҗиде «сары лира» күндерделәр. «Сары лира» дигәне Солтан Мәхмәт бишнең тәхеткә менүенә ун ел тулу мөнәсәбәте илә басылган 7,2 грамм авырлыктагы алтын тәңкәләр иде. Аллаһыбызга мең шөкерләр әйтеп, солтанга озын гомерләр теләдек. Бик сөендек. Исән-сау гомер итә башлавыбызга өмет килде. Әмма бер әйбергә игътибар иттек. Бер алтын артык иде. Ялгыш җибәргәннәр диган уйга килдек. Башкалар хакына керә алмыйбыз, ап-ачык. Башкалар хакын ашаудан Аллаһым сакласын. Безгә кадәр Төркиягә килеп урнашканнардан, әтиемнең кардәше Бурсага солтан хакимияте кешеләренә бер алтынны кире тапшырырга китте. Тегендәгеләр: «Бу заманда бу кадәр дөрес адәмнәр бармы?!» – дип, хәйран калганнар. Үзләре озак та үтми, кире унҗиденче алтынны кабат китереп бирделәр безгә. Аннары Искешәһәрдә поезд станцияләре тирәсендәге мәхәлләдән җир күрсәттеләр. Бу юлы башка борчуга төштек: «Поездлар еш йөри, тегеннән-моннан килүчеләр күп. Коммунистлык тиз килер бирегә. Иң яхшысы – без агар суы булган җир сорыйк, шундыйрак бер урынга урнашыйк». Шуннан соң безнең кебек үк мөһаҗир карачайлар корган үндүрт авыл уртасына, туган ягыбызны хәтерләткән елга янындагы җирлеккә урнаштырдылар...»

Янә җомга җитте. Бу юлы Мөнир карт намазны мосафиры белән бер рәткә басып кылды, чәй эчәргә янына башка кешене чакырырга ашыкмады. Бары егетне кайгыртты, чәй китертте.

– Минем бабам Шакирҗан исемле. Аның әтисен белмим, әнисенең исемен беләм. Кем әле... Ни... Китапка язылган. Бабамнар мәмләкәттән өч кардәш чыкканнар. Берсе әле бала икән, өйләнмәгән, ул ияреп килгән. Юлда, Кырым туфракларында күп зәхмәт чиккәннәр. Әтием аңлата иде. Галәмәт кыенлыклар күргәннәр мескеннәр. Инкыйлабчылардан качканнар, авылда кала алмаганнар инде. Дин бетә дип, динчеләрне харап итәләр дип, чыгып киткәннәр.

Карт 120 еллык, кулдан кулга, буыннан буынга күчә килгән мөһаҗирлек шаһитын ипләп кенә куеныннан чыгарды.

– Бабам Шакирҗан бу Коръәнне үзенең куенында яшереп китергән. Ни кара урманда, ни такыр юлда онытып калдырмаган, ни сулар кичкәндә җуймаган. Коръән-хафизлыгы көчле иде, иске төрекчә белән Коръәннең чит-читләренә башларыннан кичкәннәрне язып барган. Кайчан, ничек авылдан чыгып киткәннәрен. Кемнәр белән очрашканнарын. Кемнәр белән мөһаҗирлектә йөргәнен, Төркиядә авыл салганнарын. Әүвәлге картларны язган... Бабамның хатирәләрен Коръән саклый. Бер гасырны кичте инде. Башта әтием кулында иде, аннары миңа күчте. Хәлем әйбәтрәк көннәрдә рухларына багышлап хәтем чыгам, шөкер. Алай да... Ана карынынан килдек базарга, кәфен алдык, китәбез мизарга. «Үлсәм-нитсәм, хатирәләрем», – дип, Коръәнне сакларга балаларга әйтеп куйдым...

Илнур шактый тузган, һәр бите, һәр буш җире иске имлада язылган җөмләләр белән тулы басма китапны бер ачты, бер япты. Бабай өчен никадәр кадерле ядкәр булуын чамалады, аңлады кебек.

– Баштарак мәмләкәт белән хат алышып торганнар, элемтәләр өзелмәгән. Безнекеләр, көннәрдән бер көнне кайтырбыз, дигәннәр. Соңрак килгән мәктүпләр белән өметләре киселә барган. Фотоларда күренә: мәмләкәттә калганнар гел утырып төшкәннәр, ә мондагылар – аякта. Үзара шулай аңлашканнар. Кем рәхәт һәм тыныч яшәсә... Мөселманлык өчен газап чиктермәсәләр... Дин сәбәпле золым кылмасалар... Аякта төшсен. Киресе икән, утырып. Әй, дөнья, ниләр бар?! Ниләр булды?!

Сәламнән соң бер сүз эндәшмәгән, алай да картның сөйләнүен ипле генә тыңлап утырган егетнең, ниһаять, теле ачылды:

– Мөнир абый, чәйләрегез өчен рәхмәт. Иртәгә Казанга китәм.

– Бабам мәмләкәтне бик сагынды, кайта алмады. Әтиемә, миңа да күрергә насыйп итмәде. Шушы мәмләкәттән килгән Коръән кайтсын. Балаларым өчен истәлекләрне төрекчәгә әйләндереп күчердем, тапшырдым. Ә бу китапны... Казанга алып кайт.

Юл кешесе моңдый хикмәтле йөк белән йөри алмас. Әле юлда тикшерә-нитә калсалар, ничек кенә бәйләнерләр. Шуңа күрә китапны алмаска карышты. Әмма карт үз сүзеннән кире кайтмады.

Илнур Коръәнне икенче көнне, юлга чыгып китәр алдыннан, мәчет эчендәге башка китаплар торган киштәгә куеп калдырды. Изге китапны укырга өйрәнүчеләр киштәсе иде, ахры. Соңгы елларны гына нәшер ителгән төрле-төрле Коръәннәр тезелгән, зурысы, кечесе дигәндәй... Мөһаҗир Коръән алар арасында төссезлеге, искелеге белән бөтенләй күзгә чалынмас кебек. Борынгылыгы, тарихилыгы, хатирәләре белән бергә киштәнең бер почмагына сыенып калды.

Һәр нәрсәнең тормышта бер кыйммәте бар. Бу кыйммәт бары тик аңар ихтыяҗ туганда уртага чыгар, диюләре хак. Илнур бер ел тулыр-тулмас кабат шушы ук мәчеткә килде. Мәҗбүр. Хәзер аның хасияте мөһаҗирләр оныгы хатирәләренә якынрак, чөнки күчмә халәт кичерә.

Теге вакыттагыча, акрын гына чәй эчеп утырганнардан Мөнир картны сораштырды, «Аллаһының рәхмәтенә кавышты», – диделәр. Ашыгып мәчеткә керде, китаплар торган киштәне карады, эзләгәнен таба алмады.

Нигә хәзер юлларга аны?! Вакытында картның гозерен ике дә уйлап тормыйча киштәгә күмдең. Китапны тапсаң, хәзер бу гозерне үти алырсыңмы?! Ярымцифрлашкан аңы бәхәскә керде, үзенекен тәкрарлады: «Дөнья алдынгы технологияләр эрасына аяк басты, яңа буын язмышында Мөнир картның бабалары күргәннәр кабатланмас, технологик заман юл куймас, иртәгә-бүген барысы хәл ителер әле».

Ахыры бар >

Фәрдия СӘФӘРГАЛИЕВА

Ырымнарга ышансак...

Тоз чәчелсә – талаш була,
Чәй чәчелсә – ни була?
Имеш-мимешкә ышанып,
Күңелләргә шом тула...
Савыт-саба ватылганда,
Бәхеткә булсын, дибез.
Бәхет-шатлык биләгәндә
Без кайгыны белмибез.
Ватылу, җимерелүләр
Нинди бәхет булсын ди?!
Җаныбызга каян килеп
Иман нуры кунсын ди?!
Дөньялар имин булганда
Моң балкыта күңелне.
Моңлылар нечкә күңелле,
Җыр бизәсен гомерне.

***

Кайгыларым йөрәк тулы,
Ялгышларым үзем белән...
Нигә булган, нидән булган,
Барысын беләм, барысын беләм...
Гомер юлым чуар келәм,
Келәм буйлап атлап киләм...
Тирә-якта тар күңелләр...
Барын беләм, барысын беләм...

***

Санадым күкләргә карап
Якты йолдызлар санын.
Күкләрдән ниләр эзлисең,
Йолдызлар санап, җаным?
Җирдән узган язмыш юлын
Күктән барлыйсыңмы әллә?
Йолдызлы күкнең серенә
Төшенерме соң бәндә?

***

Киләчәктә яшәр көннәр
Күпме калган?
Бармы икән кем дә булса
Белә алган?
Узган чакта гомеркәйнең
Урталарын
Ныграк били шушы уйлар
Башкайларны...
Ярый, булсын. Белми генә
Яши бирик.
Матур уйлыйк, матур эшлик,
Матур сөйлик.
Кичәсе көн якынлашып
Килеп җиткәч,
Үкенмичә китәсене
Белеп йөрик.
Китәсе бар, китәсе бар,
Китәсе бар...
...Менә шулай...
Олыгая барган саен
Күңелләрне биләп ала
Сагыш, моң-зар...

***

Көнчелек кертмә уеңа,
Явызлыкны да кертмә.
Күңел сафлыгың җуймыйча
Яшәче туган җирдә.

***

Сөенеп күккә карадым,
Назлап исте җилләрем.
Кояш елмаеп карады,
Өметле иртәләрем.

- Дини жыр
- Домен
- Дурова шәһәре
- Ким киресе
- ... кыргыры
- Агач фунда-менты
- Мульт-ишәк
- Белмәгән бүрәнәдән дә ...
- Идел бурлак-ларын язган
- Погонлы качкын
- Казан артында ... чишмәсе
- Такташ, Атласи
- Аяк-куллары сызлаусыз
- ...-баба рухы
- Суы ака торур
- Гаепле сүзче
- ТР районы
- «Яшәү ...» жыры
- Казанда коттедж бистәсе
- Пушкин ахире
- Гарь
- Жырчы ... Ваенга
- ... Ширмән
- Тарала торган
- Балык тоткыч
- Ал киресе
- Дәүләт Советы вәкиле
- Тамак даруы
- Куак
- Авыздан сүз чыгару
- Чүпрәле районы авылы
- СССРда беренче жиңел авто
- Хатынның энесе
- Нота
- Әкияти шахмат фигурасы
- Гарәп хәрефе
- Мәйдан берәмлеге
- Каникул
- Уттан яратылган
- Фольк-лорчы Хәмит ...
- Йөз белән күрсәтү
- «Бабай ...» этно-комплексы
- МИД сүзчесе ... Захарова
- Төрки яугир
- Ат бавы
- Сүз төркеме
- ... дөнья
- ...-том
- Балет йолдызы
- Арчада елга
- Процентлы гөнаһ
- Боксчы
- Чыктым ... күпер
- «Әй, ... кош»
- Диңгез басмасы
- Габдинова
- Чүп үләне
- Әлипәгә әмер
- Театрлы Кәрим





Сканворд җаваплары

Горизонталь: мөнәҗәт, Алабуга, артык, мур, Репин, сау, һади, Чаадаев, Елена, Халисә, ятьмә, депутат, лума, арт, НАМИ, каениш, әйтү, алфил, ял, иблис, утары, Мария, янычар, прима, им, риба, аша, асыл, алабута, Тинчурин.

Вертикаль: Миңнекаев, Шәймурзина, дезертир, Уби, Ахун, ля, ата, тамыр, аңламас, пирс, ру, Итил, Ярми, Стрепсилс, фани, бас, Иа, Әлки, ым, Ашыт, акланучы, уалучан, Али, яме, та, Алтан, ар, ияр, алмашлык, әр, Аппакова, Тәхбәтуллин.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Беләсең килсә...

1 Советлар Союзында бу спорт төрен тыйганнары булмады:
а) каратэ;
б) бобслей;
в) бильярд.

2 1,609344 чакрым ул:
а) 1 миль;
б) 1 ярд;
в) 1 фут.

3 «Феррари» автомобиле логотибында нәрсә сурәтләнгән?
а) арыслан;
б) юлбарыс;
в) ат.

4 Жырчы Валериянең чын исеме ничек?
а) Антонина;
б) Анна;
в) Алла.

Җаваплар: 1.б); 2.а); 3.в); 4.в).

Уйнаш уйлар

***

Аерылышу турында карар еш кына өч кеше тарафыннан кабул ителә.

***

Беренче 25 елда тешләрең синә эшли, аннары син тешләреңә эшли башлыйсың.

***

Мин кечкенә шәһәрдә яшим. Шуңа күрә, танышканда, үзең турында сөйләп торасы юк.

***

Тәнкыйтькә мин бик тә уңай карыйм. Иң мөһиме ул миңа карата булмасын.

***

Жир шарындагы 100 килограмм башка планетада 16 килограммга тиң. Син таза түгел. Син бүтән планетада тугансың.

***

Химия шул ук физика сыман инде ул, әмма башка кабинетта.

***

Узган ел иң кирәксез документ дип чит ил паспорты танылды. Аңарчы лидерлыкта СНИЛС иде.

***

Хатыным мине өч бала белән ташлап (олы малайга – 7 яшь, кызга – 4 яшь, иң кечесенә – 3 атна), кухняга чәй эчәргә чыгып китте. Миңа нишләргә?

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ

Газета Элемтә, мәгълумати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 11272 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 218

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – **газета килмәсә яки соңарып килсә**

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+